
МЕТОДИК ӘСБАП

# ӘДӘБИ УКУ

# 1

Д.М.Абдуллина, Г.Н.Мөхәрләмова



Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова

# ӘДӘБИ УКУ

## МЕТОДИК ӘСБАП

1

Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Казан
2023

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
А13

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтында эшләнде

**Абдуллина Д.М.**

А13 Әдәби уку. 1 нче сыйныф. Методик әсбап : Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар өчен / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 64 б.

Методик әсбапта 1 нче сыйныфта «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметы буенча дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләре үрнәкләре бирелә.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2023
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2023
© Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н., 2023

## УКЫТУЧЫГА

Хөрмәтле хезмәттәшебез, син яңа дәреслекне кулыңа алдың. Ул хәзерге катлаулы заманда туган телен һәм милли асылын югалтмаган лаеклы гражданин тәрбияләү бурычын тормышка ашыруга ярдәм итәр.

Башлангыч белем бирү системасында «Әдәби уку» предметының үз урыны бар. Бу аның «Әлифба» китабыннан соң укучыны яңа этапка алып чыгуы белән генә дә бәйле түгел. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләбеннән чыгып караганда, «Әдәби уку» предметының максатлары һәм бурычлары элеккеге «Уку» предметыныкыннан шактый аерыла. Ул уку тизлеген арттыру, аңлап уку, укыган әсәрнең эчтәлеген сөйләү, план төзү, әсәрне өлешләргә бүлү, эчтәлеккә кагылышлы сорауларга җавап бирү кебек төп эшләр белән беррәттән, әсәрне сәнгатьнең бер төре буларак кабул итәргә өйрәтә. Бу – баланың укыганны хисләр дәрәҗәсендә кабул итүенә ирешү. Шуның белән ул аның рухын тәрбияли, шәхес буларак камилләштерә, фикерләргә, чагыштыру-анализлау ярдәмендә нәтиҗәләр ясарга, тормышчан ситуацияләрдә аларны куллана белергә өйрәтә. Моңа ирешү юлында төп ике каршылыкны үтеп чыгарга кирәк. Беренчесе – укучының әсәрне тулысынча аңлавына ирешү. Балалар татар телен начар белгән очракта, хәл тагын да катлаулана. Дәрестә сүзлек белән эшләүгә җитәрлек вакыт бирү таләп ителә. Икенчесе – әдәбияттагы шартлылык, образлылык һәм образ тудыру чараларын аңлы рәвештә кабул итү, шартлылык артына яшеренгән мәгънәне таба белү. Болар һәммәсе дә «Әдәби уку» предметы алдында гына торган бурычлар түгел, әмма «Әдәби уку» дәресләрендә шул югарылыкка ирешүнең беренче адымнары ясала. Кече яшьтәге мәктәп балалары, әсәрне укыганда, беренчел, өстә яткан эчтәлекне кабул итә. Әсәрдәге геройлар, образлар чынбарлык буларак күзаллана. Шуңа әсәрне кабул иткәндә, хисләр дә тирәнрәк һәм тәэсирлерәк була. Бала өчен хисләр туу бик тә әһәмиятле. Ул аның рухи-әхлакый кыйммәтләрен формалаштыра, башкаларның хис-

ләрен аңларга, аны уртаклашырга өйрәнә. Укыганны чынбарлык белән тагын да ныграк якынайта. Хис-кичерешләрдә дә яңа дулкын тудыра. Анализлау, чагыштыру, башкалар фикерен тыңлау, сайлап алу, нәтиҗә ясау ярдәмендә укучының үз фикере формалаша. Ул әдәби әсәргә кагылышлы фикер генә түгел, тормыштагы аерым бер ситуацияне дөрес хәл итүнең чишелеше буларак, практик куллану мөмкинлеге булган белемнән гыйбарәт. Әдәби әсәрне укыганда әлеге эзлеклелекне саклау нәтиҗәсендә укучы аңлы, укудан тәм таба торган шәхес булып җитешә.

Балалар төрле вакытта укырга өйрәнә, әмма укытучы дәрестә аларны максатчан рәвештә аңлап укырга өйрәтә. Сүзнең мәгънәсе белән аның график гәүдәләнеше хәтердә булганда, уку һәм укыганны аңлау процессы күпкә тизләтелә. Бу – сүзләрне дөрес укырга да ярдәм итә. Иҗекләп укыганда, укучы минутына 20–30 сүз генә укый алса, беренче сыйныфны тәмамлаганда исә, йөгерек укырга өйрәнеп, 40 сүз укырга тиеш. Шуның өчен иң элек иҗекләп түгел, ә сүзләп укый алуга ирешү дә бик мөһим. Билгеле, бу баладан да, укытучыдан да тырышлык һәм вакыт таләп итә. Әмма шуңа ирешмәгәндә, аңлап уку һәм укыганны күңеле аша үткәрү мөмкин түгел, бу очракта бала укуның тәмен тоймый, канәгатьләнү хисе кичерми.

Дәреслеккә кертү өчен әдәби текст сайлаганда, классик язучыларның әсәрләре генә алынмый. Сәнгать ягыннан түбән эшләнелгән әсәрләр алу укучыга әдәби әсәрне кабул итәргә комачаулаган кебек, кече яшьтәге балага әдәбият белеменә караган авыр материалны күпләп тәкъдим итү дә зыян сала. Шуңа күрә сайланган әсәр балага акыл һәм хис белән кабул итү өчен җиңел булырга һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүгә дә хезмәт итәргә тиеш.

Укырга өйрәнүне уку техникасына һәм сәнгатьлелеккә генә кайтарып калдырырга ярамый. Аңлап уку белән керешкәндә генә, ул укучы өчен нәтиҗәле була.

Укырга өйрәнү чорында балага укып күрсәтү бик мөһим, чөнки кече яшьтәгеләр кабатлауга, ияреп эшләүгә бик тә сәләтле. Бу укытучыдан да зур җаваплылык таләп итә, чөнки укучы телне нәкъ аның үрнәгендә өйрәнә. Әлеге дәреслекнең электрон

вариантында күп әсәрләрнең аудиоязмалары урнаштырылу бу мәсьәләне хәл итәргә ярдәм итә.

Туган телдә (татар телендә) әдәби уку курсы укучыларның милли мәдәният белән кызыксынуын формалаштыра, милли мохиткә алып керә, татар әдәбияты һәм сәнгатеннән кирәкле мәгълүмат эзләү, табу мөмкинлекләренә өйрәтә.

Программага жанр һәм тематик яктан бай, эстетик һәм әхлакый кыйммәте югары, укучыны кызыксындыра алырлык татар балалар әдәбияты һәм татар фольклорының иң яхшы үрнәкләре сайлап алынды. Әдәби материал татар халкының этномәдәни мирасын чагылдырырлык тематик бүлекләр кысаларында укучыларның яшь үзенчәлекләренә тәңгәл китереп тәкъдим ителә.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын 2 сәгать укыту мөмкинлеге булган очракта тәкъдим ителгән темалар икешәр сәгать өйрәнелә. Дәреслектә өстәмә материал бар.

Программада әхлакый камиллек, җаваплылык, патриотик хисләр, туган якка, Туган илгә мәхәббәт тәрбияләүгә, укучының үз милли тәңгәллеген аңлы кабул итүенә ныклы игътибар бирелә.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметының төп **максаты** – татар мәдәниятенең мөһим өлеше булган туган (татар) телдәге әдәбиятка сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, укучыларның мәдәни мираска, үз халкының гореф-гадәтләренә тартылуын тәэмин итү, киләчәктә куелган уку бурычыннан чыгып, шулай ук үзләре кызыксынган өлкәгә караган әсәрләрне китапханәләрдән мөстәкыйль рәвештә сайлап алырлык грамоталы укучы формалаштыру.

Максатларны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итә:

- укуга һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, укучының тормышны күзаллавын формалаштыру;
- укучыларның аралашу (коммуникатив) сәләтен булдыру;
- укучыларның туган (татар) телендә телдән һәм язма диалогик, монологик сөйләмен үстерү;
- кычкырып һәм эчтән (үз-үзеңә) уку техникасын булдыру һәм камилләштерү, текстны төшенү (кабул итү һәм аңлау) алымнарын үстерү, эшчәнлекнең универсаль төрләренә – күзәтүгә, чагыштырма анализга өйрәтү;

- әдәби анализ элементларын куллану аша укучыларны сүз сәнгатенә, туган телдәге әдәбиятка якынайту, аерым әдәби-теоретик төшенчәләр белән таныштыру;
- укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру, әсәрләрнең рухи асылын аңларга өйрәтү;
- туган (татар) телендә иҗади эшчәнлек сәләтләрен үстерү.

Укыту барышында сыйныфларда белем бирү эчтәлеге түбәндәге эшчәнлек төрләре белән үрелеп бара.

**Тыңлау.** Укытучы һәм сыйныфташлары тарафыннан кычкырып укылган текстны, әңгәмәдәшләренең фикерләрен, үзенә бирелгән сорауларны аңлау. Әйтелгән (ишеткән) сүзнең мәгънәсенә төшенү: фикер алышу аспектын тотып алу, сөйләм эчтәлеге нигезендә сорауларга җавап бирү һәм үз сорауларыңны формалаштыру.

**Кычкырып уку.** Иҗекләп укудан сүз белән укуга күчү, уку тизлеген акрынлап арттыру. Рольләргә бүлеп уку, чылбыр буенча уку барышында кычкырып уку техникасын формалаштыру. Сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү (башлангыч этапта җөмләләрне тыныш билгеләренә карап, интонацион буыннарга аерып, дөрес итеп, жанр таләпләренә туры китереп уку).

**Үзлегеннән уку (эчтән уку).** Күләме зур булмаган текстны мөстәкыйль уку. Өйрәнелә торган текстта кирәкле мәгълүматларны, аңлашылмаган сүзне сүзлектән табу һәм сайлап уку ярдәмендә төп мәгънәне истә калдыру.

**Сөйләү.** Монологик сөйләм төрләрен үзләштерү: сорауга кыска яисә киңәйтелгән җавап рәвешендә; текстны укудан туган үз тәэсирләрен, тормышны күзәтүләреннән туган тәҗрибәне тапшыру рәвешендә; фикерне текстка таянып дәлилләү рәвешендә (текстта кирәкле урынны табып уку). Диалогик аралашу үзенчәлекләрен үзләштерү: әңгәмәдәшенең әйткәннәрен тыңлый һәм аларга карата үз мөнәсәбәтен белдерә белү (ризалашу / килешмәү). Текст эчтәлегенә таянып, үз фикерләрен дәлилләп яклый белү.

**Язу.** Текст төрләренең аермасын тану (текст-хикәяләү, текст-тасвирлау, текст-фикер йөртү) һәм аларны кечкенә сочинениеләр формасында практик үзләштерү; шәхси күзәтүләр һәм тәэсирләр нигезендә кыска сочинениеләр язу.

**Әдәби әсәр тексты белән эшләү.** Текстның исемен анализлау, сораулар һәм биремнәр системасы аша текстны тикшерү, төп эмоциональ-мәгънәви берәмлекләрен ачыклау (төп фикер, лирик шигырьдә төп кичерешләр, геройларның капма-каршы позицияләре һәм хикәядә автор нәтиҗәсе). Текст төзелешенең үзенчәлекләрен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын ачыклау (антонимнар, синонимнар, сынландыру, чагыштыру). Геройның холкын билгели белү (сүз ярдәмендә тудырылган портреты аша, гамәлләрен анализлаудан, сөйләм үзенчәлегеннән чыгып, автор аңлатмалары ярдәмендә), башка геройларның үз-үзләрен тотышына чагыштырма анализ, укытучы ярдәмендә проза әсәрләрендә автор позициясен һәм лирик әсәрләрдә автор кичерешләрен таба белү. Текст белән эшләгәндә, төрле сюжет сызыкларын аерып чыгара белү; эчтәлек ярдәмендә карашлар һәм позицияләрнең төрлелеген күрергә өйрәнү; сюжет үстерелешендә һәм геройларның эш-гамәлләрендә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; автор фикерен аңлау; текстның төп фикерен аерып чыгару; тел-сурәтләү чараларын табу.

**Балалар өчен әсәрләр.** Халык авыз иҗаты әсәрләре. Фольклорның кече жанрлары (санамышлар, табышмаклар, эндәшләр); халык әкиятләре (хайваннар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, тылсымлы әкиятләр); мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр. Автор әкиятләре, мәсәлләре, авторларның әдәби әсәрләре. XIX–XX гасырларда туган телдәге (татар) әдәбият классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр). Туган телдәге (татар) балалар әдәбияты классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр). Төрле халыклар (Россиянең күпмилләтле дәүләт булуын исәпкә алып) әдәбияты үрнәкләре (хикәяләр, әкиятләр). Балалар өчен вакытлы матбугат басмалары (журналлар).

**Әдәби пропедевтика**. Төрле типтагы рифмалар, халык иҗаты һәм автор әдәбияты әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен тану, әдәби әсәрләрдәге тел-сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, сынландыру, чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар һ.б.) белән танышу һәм аларның кулланылу үзенчәлеген аңлау.

Укучыларның татар халык иҗатының кече жанрлары турындагы белемнәрен системалаштыру һәм «халык авыз иҗаты» төшенчәсен үзләштерү. Әдәби күзаллау алымнарын формалаштыру. Фольклор әсәрләре турында билгеле бер караш булдыру. Фольклор әсәрләренең жанр төрлелеген (хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре; кече фольклор формалары: табышмаклар, санамышлар, бишек җырлары, мәкальләр һ. б.) ачу.

Автор әдәбияты: хикәя, әдәби әкият жанры, шигырьләр. Шигырьнең үзенчәлекләре (ритм, рифма). «Тема» һәм «төп фикер» төшенчәләре. Төрле жанрдагы әсәрләрне практик тану («жанр» төшенчәсен үзләштермичә). Әсәрнең герое, хикәяләүче һәм автор турында күзаллау тудыру.

Текстның халык авыз иҗаты яки автор әсәре булуын билгеләү. Текстның жанр үзенчәлекләре (әкият, хикәя, шигырь, мәкаль, табышмак һ.б.). Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар арасындагы аерманы, проза һәм шигырь текстларының аерымлыкларын күрсәтү. Әдәби әсәрдә автор позициясен табу (укытучы ярдәмендә), шулай ук геройның (лирик геройның) кичерешләрен аңлау.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге.** Әдәби әсәрне (яки аның аерым өлешләрен) рольләргә бүлеп уку. Шигырь һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый белү. Интонация, уку темпын аңлы рәвештә сайлый һәм текст үзенчәлекләре нигезендә кирәкле паузалар ясый алу. Дәреслектәге иллюстрацияләрне анализлый белү, аларны әдәби текстлар белән чагыштыру. Кече фольклор жанрларын практик үзләштерү (табышмаклар, санамышлар, эндәшләр), үз текстын иҗат итү һәм аны тәэсирле чаралар (мимикалар, ишарәләр, интонацияләр) ярдәмендә инсценировкалау. Телдән һәм язма рәвештә (аерым җөмләләр һәм зур булмаган сочинениеләр рәвешендә) үзеңнең шәхси күзәтүләрең һәм тәэсирләрең белән уртаклаша алу.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәләре башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартында формалаштырылган төп белем бирү программасын үзләштерү буенча «Туган тел һәм туган телдә әдәби уку» предмет өлкәсе нәтиҗәләренә карата куелган таләпләргә туры килә.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү укучыларда тәрбия эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча тәкъдим ителгән түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр формалаштырачак:

***патриотик һәм гражданлык тәрбиясе:***

- үз Ватанына — Россиягә югары кыйммәт итеп карау, шул исәптән илнең тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган сәнгать әсәрләрен өйрәнү аша да;
- үзеңнең этномәдәни тәңгәллегеңне һәм Россия гражданины булуыңны аңлау;
- үз илеңнең һәм туган ягыңның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйләнеш тою, шул исәптән сәнгать әсәрләрен өйрәнү барышында фикер алышу аша да;
- үз халкыңа һәм башка халыкларга хөрмәт белән карау, шул исәптән әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләре аша да шундый ук хөрмәт тәрбияләүгә ирешү;
- әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләрендә урын алган кыйммәтләргә, әдәп-әхлак нормаларына таянып, һәм гомумән, җәмгыятьнең бер әгъзасы булган кеше, аның хокуклары һәм бурычлары, хөрмәткә лаек булуы һәм абруе, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр турында беренчел күзаллау туу;

***рухи-әхлакый тәрбия:***

- уку нәтиҗәсендә һәм шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянып, һәр кешенең индивидуаль шәхес булуын тану;
- тел нормалары, сөйләм әдәбе чикләрендә кешенең хәленә керү, хөрмәт һәм шәфкатьлелек күрсәтү, үз халәтен һәм хисләрен белдерү; башка кешеләрнең тойгыларын аңлау һәм уртаклашу, теләктәшлек күрсәтү;
- яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү, конфликтлар булдырмау һәм бәхәсле хәлләрдән чыгу юлларын табу, шул исәптән әдәби әсәрләр үрнәкләренә таяну;

***зәвык тәрбияләү:***

- мәдәниятебезне хөрмәт итү һәм аның белән кызыксыну, сәнгать төрләренә, үзеңнең һәм башка халыкларның традицияләренә, иҗатына ихтирам белән карау;
- сәнгатьнең төрле юнәлешләрендә, шул исәптән сүз сәнгатендә үз-үзеңне күрсәтергә, танытырга омтылу;
- физик тәрбия, сәламәт яшәү культурасы һәм эмоциональ тотрыклылык формалашу;
- әйләнә-тирә мохиттә өстәмә мәгълүмат эзләгәндә (шул исәптән цифрлаштырылган информацион кырда да), үзеңә һәм башкаларга мөнәсәбәттә сәламәт һәм имин яшәү кагыйдәләрен үтәү;
- үз фикереңне җиткерүнең кулай ысулларын сайлау, сөйләм этикеты нормаларын һәм аралашу кагыйдәләрен үтәү нигезендә физик һәм психик сәламәтлеккә зарар китермәү;

***хезмәт тәрбиясе:***

- кеше һәм җәмгыять тормышында хезмәтнең югары кыйммәт булуын (шул исәптән әдәби әсәрләрдән алынган мисаллар ярдәмендә дә) аңлау, хезмәт нәтиҗәсенә җаваплы караш һәм сакчыл мөнәсәбәт, эшчәнлекнең төрле төрләрендә катнашу күнекмәләре, әдәби әсәрләр турында фикер алышу барышында танышкан төрле һөнәрләр белән кызыксыну;

***экологик тәрбия:***

- текстлар белән эшләү барышында табигатькә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- үзенә зарар китерә торган гамәлләрне кабул итмәү;

***фәнни танып белү кыйммәтләре:***

- дөньяның фәнгә нигезләнгән картинасы турында беренчел күзаллаулар барлыкка килү, шул исәптән кайбер әдәби төшенчәләрне үзләштерү барышында да;
- танып белү мәнфәгатьләре, танып белүдә активлык, инициативалылык, кызыксыну һәм мөстәкыйльлек, шул исәптән әдәби әсәрләрне укуга игътибарлы мөнәсәбәт, уку даирәсен киңәйтүдә активлык һәм мөстәкыйльлек.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәсендә, укучыларда түбәндәге танып белү универсаль уку гамәлләре формалашачак.

***Төп логик гамәлләр:***

- төрле текстларны чагыштыру өчен нигезләр табу, текстларның охшашлыгын билгеләү;
- аерым бер билге буенча объектларны (текстларны) берләштерү;
- мәкальләрне, әйтемнәрне, фразеологизмнарны классификацияләү өчен төп үзенчәлекне билгеләү;
- укытучы тәкъдим иткән күзәтү алгоритмы нигезендә текстларда закончалыклар һәм каршылыклар табу; текстны тикшергәндә кулланылган гамәлләрнең алгоритмын анализлау, әлеге гамәлләрне мөстәкыйль рәвештә аерып күрсәтү;
- тәкъдим ителгән алгоритм нигезендә өйрәнү һәм гамәли бурычны хәл итү өчен, мәгълүматның җитмәвен ачыклау, җитешмәгән өстәмә мәгълүматны эзләргә өйрәнү;
- текстны анализлаганда, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр ясау.

***Төп тикшеренү гамәлләре:***

- укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, сөйләм ситуациясе нигезендә үз фикереңне җиткерүне планлаштыру;
- биремне үтәүнең берничә вариантын чагыштыру, тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә аеруча туры килә торганын сайлау;
- бирелгән план нигезендә катлаулы булмаган кечкенә тикшеренү үткәрү, проект биремен үтәү;
- нәтиҗәләрне формалаштыру һәм аларны текстка ясалган мәгънәви анализ нәтиҗәләре белән дәлилләп ныгыту; тәкъдим ителгән текстны анализлау барышында укытучы ярдәмендә сораулар формалаштыру;
- вакыйгалар, хәлләрнең мөмкин булган үсешен һәм бердәй яки охшаш шартларда аның нәтиҗәләрен фаразлау.

***Мәгълүмат белән эш:***

- мәгълүмат алу, төгәллек кертү чыганагын сайлау: кирәкле сүзлек, белешмәлек һ.б;
- бирелгән эш тәртибеннән чыгып, тәкъдим ителгән чыганактан (сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән) төгәл мәгълүматны табу;
- мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны (сүзлекләргә, белешмәлекләргә, дәреслеккә мөрәҗәгать итеп) танып белү;
- Интернетта мәгълүмат эзләгәндә, өлкәннәр (педагогик хезмәткәрләр, ата-аналар яки аларны алмаштыручы законлы вәкилләр) киңәшен тотып, мәгълүмати иминлек кагыйдәләрен үтәү;
- уку бурычы таләбеннән чыгып, текст, график, видео, аудиоязма хәлендәге мәгълүмат булдыру һәм анализлау;
- таблица, схема рәвешендә китерелгән мәгълүматны аңлау; текстлар белән эшләүнең нәтиҗәләрен күрсәтү өчен, схемалар, таблицалар төзү.

Башлангыч мәктәп курсын тәмамлаганда, укучыда коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалаша.

***Аралашу:***

- таныш мохиттә аралашу максатларыннан һәм шартларыннан чыгып, әйтелгән фикерләрне кабул итү һәм үз фикерләрен формалаштыру, хис-кичерешләрне белдерү;
- әңгәмәдәшкә хөрмәт саклау, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү;
- карашлар төрле булу мөмкинлеген тану;
- үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү;
- сөйләмне куелган бурычка нигезләнеп төзү;
- сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар (тасвирлама, фикер йөртү, хикәяләү) булдыру;
- парлап һәм төркемдә эшләү, кечкенә тикшеренү, проект биреме нәтиҗәләре турында кыскача чыгышлар әзерләү;

- чыгыш текстына күргәзмә материал (рәсемнәр, фоторәсемнәр, плакатлар) сайлау.

***Күмәк эшчәнлек:***

- типик шартларда күмәк бурычны үтәү өчен, укытучы тәкъдим иткән планга сыешырлык итеп, үзең өчен кыска һәм дәвамлы вакыт аралыгына максатлар, аңа ирешү алымнарын һәм вакытын билгеләү;
- уртак эшчәнлекнең максатын аңлау, аңа ирешү өчен, күмәк гамәлләр кылу: килешенеп вазифаларны бүлү, уртак эш барышы һәм нәтиҗәсе турында фикер алышу;
- җитәкчелек итү, йөкләмәләр башкару; буйсынырга, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә әзерләү;
- үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру;
- гомуми нәтиҗәдә үзең керткән өлешне бәяләү;
- тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

Башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганда, белем алучының түбәндәге **регулятив-универсаль уку гамәлләре** формалаша.

***Оештыру:***

- нәтиҗәгә ирешү өчен, уку бурычын хәл итү эзлеклелеген планлаштыру;
- сайлап алынган гамәлләрнең эзлеклелеген булдыру.

***Үз-үзеңне тикшерү:***

- уку эшчәнлегенең уңышы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен билгеләү;
- сөйләм хаталарын һәм текстларны анализлауга бәйле хаталарны булдырмау өчен, үзеңнең уку эшчәнлегеңә төзәтмәләр кертү;
- эшчәнлек нәтиҗәсен текстларны анализлауга куелган уку бурычы белән чагыштыру;
- текстлар белән эшләгәндә җибәрелгән хатаны табу;
- үз эшчәнлеге һәм сыйныфташлары эшчәнлеге нәтиҗәләрен чагыштыру, аларны тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә объектив бәяләү.

**Предмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын дүрт ел дәвамында өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итәргә тиеш:

- татар әдәбиятын дөньякүләм һәм милли мәдәният күренеше, тормышны танып белүнең махсус ысулы, халкыбызның милли-мәдәни байлыгы, әхлакый кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау һәм тапшыру чарасы буларак аңлау;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү нигезендә татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау;
- туган телдәге әдәбиятны укуның шәхси үсеш, үзеңне, дөньяны, милли тарихны һәм мәдәниятне танып белү; мәдәни тәңгәллегеңне тану; татар әдәбиятын системалы укуга ихтыяҗ булдыру өчен, аның мөһимлегенә төшенү;
- укылган әсәрдәге каһарманнар гамәлләренең әхлакый нормалар белән тәңгәллеген ачыклау, әлеге гамәлләрне әхлакый бәяләүне нигезләү;
- метафораларның, сынландыруларның, эпитетларның милли үзенчәлеген аңлау;
- уку күнекмәләрен камилләштерү (кычкырып һәм эчтән уку, интерпретациянең элементар алымнарын белү, әдәби, фәнни-популяр текстларны анализлау һәм үзгәртеп кору);
- татар әдәбияты әсәрләрен уку тәҗрибәсен мөстәкыйль куллану (тыңланган / укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, текстка сылтамалар белән үз фикереңне исбатлау һәм раслау; текст үзенчәлеген саклап, тыңлаган яки укыган текстның эчтәлеген кыскача яки тулысынча сөйләү; укылган әсәрләр нигезендә коммуникатив бурычны (төрле адресат өчен) исәпкә алып, телдән хикәя төзү, шигъри әсәрләрне яттан уку);
- кызыксындырган әдәбиятны мөстәкыйль сайлау һәм кызыксыну чикләрен киңәйтә бару;

өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан файдалану.

**Уку елы тәмамланганда татар телендә белем алучы 1 нче сыйныф укучысы:**

- кычкырып укырга (хәрефләрне һәм иҗекләрне төшереп калдырмыйча, урынын алыштырмыйча, иҗекләп түгел, сүзләр белән дөрес уку техникасына ия булу), текстның үзенчәлекләре нигезендә интонацияне, уку темпын һәм кирәкле паузаларны аңлы рәвештә сайларга;
- телдән бирелгән сорауларга җавап бирергә, үз җавабын тексттагы мисаллар белән расларга, әсәрнең төгәл эчтәлегенә сораулар бирергә; укылган текст буенча әңгәмәдә катнашырга;
- укылган яисә тыңланган текстның укытучы ярдәмендә темасын һәм төп фикерен билгеләргә;
- әдәби геройны тасвирларга, аның эш-гамәлләренә бәя бирергә;
- төрле авторларның бер-ике шигырен яттан сөйләргә;
- укытучы киңәше буенча мөстәкыйль уку өчен китап сайларга;
- укылган китап турында сөйләргә (авторы, исеме, темасы);
- фольклорның аерым жанрларын (санамыш, эндәш, табышмаклар) һәм әдәби жанрларны (хикәя, шигырь) аерырга һәм әйтеп бирергә;
- проза әсәрен шигъри әсәрдән аерырга, шигъри әсәрнең үзенчәлекләрен (рифма) аерып күрсәтергә;
- текстта сурәтләү чараларын (иркәләү-кечерәйтү, синонимнар, антонимнар) табарга;
- сәнгатьле укырга, рольләргә бүлеп укырга;
- укылган яисә тыңланган әсәр нигезендә үрнәк буенча күрсәтелгән темага телдән 2–3 җөмлә төзеп әйтергә;
- текст-хикәяләү булдырырга өйрәнә.

**рус телендә белем алучы 1 нче сыйныф укучысы:**

- кычкырып укырга (хәрефләрне һәм иҗекләрне төшереп калдырмыйча, урынын алыштырмыйча иҗекләп түгел

сүзләр белән дөрес уку техникасына ия булу), текстның үзенчәлекләре нигезендә интонацияне, уку темпын һәм кирәкле паузаларны аңлы рәвештә сайларга;

- укылган яисә тыңланган текстның укытучы ярдәмендә темасын һәм төп фикерен билгеләргә;
- әдәби геройны тасвирларга, аның эш-гамәлләренә бәя бирергә;
- төрле авторларның бер-ике шигырен яттан сөйләргә;
- фольклорның аерым жанрларын (санамыш, эндәш, табышмаклар) һәм әдәби жанрларны (хикәя, шигырь) аерырга һәм әйтеп бирергә;
- проза әсәрен шигъри әсәрдән аерырга, шигъри әсәрнең үзенчәлекләрен (рифма) аерып күрсәтергә;
- текстта сурәтләү чараларын (иркәләү-кечерәйтү, синонимнар, антонимнар) табарга;
- укылган яисә тыңланган әсәр нигезендә үрнәк буенча күрсәтелгән темага телдән 2–3 җөмлә төзеп әйтергә өйрәтә.

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

## 1 нче сыйныф

| Тема | Эчтәлек | Укучылар эшчәнлегенең төрләре |
| --- | --- | --- |
| Өйрәтәләр мәктәпләрдә (8 сәгать) | Мәктәп тормышы, дәресләр, классташлар, мәктәптәге бәйрәмнәр турында әсәрләр.<br>**Җ. Дәрзаман.** «Тискәре хәрефләр».<br>**М. Мәһдиев**. «Мәктәптә беренче көн».<br>**М. Җәлил**. «Беренче дәрес».<br>**Ш. Маннур**. «Яхшы бел».<br>**Х. Туфан**. «Казан».<br>**Б. Рәхмәт**. «Рәсемнәр ясыйбыз».<br>**Н. Мадьяров**. «Салават күпере».<br>**В. Голявкиннан** «Парта астында».<br>**Ф. Садриев**. «Тургай мәктәпкә бара».<br>Мәктәп турында «Сабантуй» балалар журналы.<br>Сыйныфтан тыш уку:<br>**З. Гомәрова**. «Әтәч рәсеме». | Әңгәмә: дәреслек, шартлы билгеләр белән танышу.<br>Текстны аңлап уку.<br>Әсәрнең гомуми эчтәлеген аңлау.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Күзәтү: иллюстрацияләр карау.<br>Әсәр героен характерлау: аның эшгамәлләрен бәяләү.<br>Терәк сүзләр нигезендә әсәрнең эчтәлеген сөйләү.<br>Парлап эшләү: үрнәк буенча диалог төзү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Күнегү: дәфтәрдә язма күнегүләрне эшләү. |

| | | |
|---|---|---|
| Минем гаиләм (5 сәгать) | Гаиләнең кеше тормышындагы урыны, гаилә әгъзалары турында әсәрләр.<br>Гаилә традицияләре, гаиләдә аралашу ситуацияләре.<br>**Г. Тукай.** «Безнең гаилә».<br>**Н. Мадьяров.** «Булышабыз».<br>**Ш. Галиев.** «Дәү әнигә күчтәнәч».<br>**А. Алиш.** «Әбиләрдә кунакта».<br>**Р. Вәлиев.** «Барысын да яратам».<br>**Г. Әдһәм.** «Кызыл муенса».<br>**Җ. Дәрзаман.** «Исем таптым!».<br>Сыйныфтан тыш уку:<br>**А. Әхмәтгалиева.** «Безнең өйдә».<br>**Т. Әйди.** «Дачада». | Текстны аңлап уку.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар белән раслау.<br>Әдәби әсәрнең текстын тикшерү: укылган текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, вакыйгаларны дөрес тәртиптә урнаштыру.<br>Әдәби геройны характерлау.<br>Парлап эшләү: үрнәккә карап диалог төзү.<br>Сөйләү: хикәяләүгә корылган текст төзү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Күнегү: дәфтәрдә язма күнегүләрне эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлау. |

| | | |
|---|---|---|
| Татар халык иҗаты. Санамышлар, эндәшләр (2 сәгать) | Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Аларның тормыштагы урыны. Куллану ситуацияләре.<br>**Санамышлар.**<br>**Эндәшләр** | Тыңлау: сүзнең аваз һәм мәгънәви ягын, тыңлаган сөйләмне аңлау.<br>Уку диалогы: сорауларга телдән җавап бирү. Сүзлек эше: сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итү.<br>Фольклорның кече жанрларын аеру.<br>Әдәби әсәр тексты өстендә эш: тексттагы образлылыкны аңлау.<br>Иҗади эш: үрнәккә карап санамышлар, эндәшләр иҗат итү. |
| Табигать яме (Красивая природа) (3 сәгать) | Табигатьнең матурлыгы, аны саклауның әһәмияте турындагы әсәрләр.<br>**И. Туктар.** «Җем-җем!.. Чвик!», «Серле тартма».<br>**Ф. Садриев.** «Яңгыр, яу, яу, яу!».<br>**Н. Арсланов.** «Яз».<br>**Ф. Зариф.** «Татлы җәй».<br>**Ш. Галиев.** «Тәмле җәй».<br>Сыйныфтан тыш уку:<br>**Р. Вәлиева.** «Кыңгырау чәчәк».<br>**С. Гаффарова.** «Гөлгүзәл». | Текстны аңлап уку.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Сөйләү: үрнәккә карап тәкъдим ителгән темага телдән сөйләү.<br>Текст белән эш: геройның хис-кичерешләрен сурәтләү чараларын билгеләү, әдәби чараларның текстта урынын табу һәм мәгънәсен аңлау.<br>Күнегү: дәфтәрдә язма күнегүләрне эшләү. Проект әзерләү: хәрефләр турында китапчык төзү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлау. |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп нәрсәләрне искәртүне генә максат итә. Күп еллар эшләгән тәҗрибәле укытучы өчен ул бик гади генә булып тоелырга мөмкин, ә беренче сыйныфлар белән үзе дә хезмәт юлына тәүге адымын ясаган хезмәттәшебезгә бу ярдәм зыян итмәс.

Дәреслектәге һәр тема өйрәнелә торган әсәр белән бәйләп бирелә. Теманы өйрәнүнең башыннан ахырына кадәр укучылар белән белемнәрне дәреслек персонаж-геройлары үзләштерә. Алар укучыларның яшьтәшләре – шагыйрь Роберт Миңнуллинның – Алмаз, Җәүдәт Дәрзаманның Гөлназ исемле лирик геройлары. Нур исемле укучы «Туган тел (татар теле)» дәреслегендә дә очрый. Ул – яхшы укучы, бик акыллы һәм зирәк, һәрвакыт киңәше белән ярдәм итә, аңлата. Аерым урынны Хөрмәтле дәреслек образы алып тора, ул, укучылар белән сөйләшүгә кушылып, үзләштерү өчен авыр һәм катлаулы материалны аңлата, үгет-нәсыйхәтен бирә.

Әлеге әдәби геройлар укучылар белән өйрәнелә торган темага һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле сөйләшү алып баралар. Персонажлар белән әңгәмә теманың башында һәм ахырында бирелә. Әлеге әңгәмәләр һәм төрле коммуникатив юнәлешле биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерүгә хезмәт итәләр. Мондый диалоглар укучыларның күңелләрен күтәрә, дәрес башында куелган уку мәсьәләсенә төшенергә булыша, теге яки бу әдәби әсәрне өйрәнүгә мотивлаштыра.

Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус), ягъни ике дәрәҗәдә укуны (предметның база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне), димәк, бер-берсеннән бик нык аерылып торган укучыларга белем бирүне күздә тота.

Дәреслектә төрле дәрәҗәдә үзләштерелә торган материаллар аерып китерелә. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен генә булган темалар дәреслек битләрендә төс һәм график сурәт

(яшел пунктирлар) ярдәмендә күрсәтелә. Сорау-биремнәр дә ике дәрәҗәгә аерып бирелә. Укытучы өчен методик әсбапта да предметны тирәнтен өйрәнү буенча киңәшләр зәңгәр төс белән билгеләнә.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча база өлешендәгеләре, укучыга авырлык тудырырлык түгел. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә материаллар, сорау-биремнәр укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлауларын күздә тота.

Әдәби тексттан соң укучыларга сүзлекчә тәкъдим ителә. Биредә текстта очраган таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә. Бу – телне төрле дәрәҗәдә белгән укучыларга әдәби текстны кабул итү һәм аңлауны берникадәр җиңеләйтәчәк.

Дәреслектә, үзләштерү өчен, әдәби-теоретик төшенчәләр дә китерелә. Аларның саны күп түгел.

Ятлау өчен бер уку елына 1–2 әсәр бирелә. Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә аларның саны бераз күбрәк.

Үткән материалны кабатлау төрле формада оештырыла. Ул традицион сорау-биремнәргә җавап бирү рәвешен дә, укылган әсәрләр буенча квест-уен, кроссвордлар чишү, дидактик характердагы төрле әдәби уеннар рәвешен дә ала.

Табышмаклар, ребуслар аерым теманы үзләштергән вакытта да тәкъдим ителә. Бу – укучыларга эмоциональ яктан тәэсир ясый, дәрескә куелган уку мәсьәләсен аңларга ярдәм итә, яңа әдәби материалны өйрәнүне мотивлаштыра.

Дәреслектәге темалар Сабантуй бүләге рәвешендә тәкъдим ителгән мәкаль-әйтемнәр, риваятьләр, тизәйткечләр белән тулыландырыла. Аларны белемнәрне ныгытканда яки дәрескә йомгак ясаганда уңышлы гына кулланып була.

Китапханәләрнең әдәбият белән тиешле күләмдә тәэмин ителмәвен, аерым әсәрләрне Интернет чыганакларда табып булмавын исәпкә алып, дәрестән тыш уку өчен кирәкле әсәрләр

дә дәреслеккә кертелде. Монда укытучының сайлап алу мөмкинлеге бар.

«Әдәби уку» дәреслеге белән «Туган тел (татар теле)» дәреслеге бер-берсен тулыландырып бара. Бу эш темаларда да, компетенциядә дә чагылыш таба. Балалар ияләшеп өлгергән персонажлар ике дәреслектә дә очрый.

Дәреслекнең электрон вариантында һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Алар балаларның кызыксыну даирәләрен, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнде. Шулай ук биредә аерым текстларның аудиоязмалары урын алган. Текст белән эшләгәндә, аларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы видеодәресләрдә дә тәкъдим ителә. 1 нче сыйныф өчен барлыгы 10 темага күләме ягыннан зур булмаган видеороликлар булдырылды. Аларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә һәм Үрнәк эш программалары нигезендә әзерләнде. Видеодәресләрнең төп максаты – укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Видеодәресләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылды.

Сыйныфтагы укучыларның гомуми мөмкинлеген һәм һәр укучының аерым мөмкинлекләрен укытучы үзе яхшы белә. Шул сәбәпле методик әсбапта бирелгән үрнәк нигезендә генә дәрес үткәрү мөмкин түгел. Бу әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмә үткәрү кебек алымнарның һәр очракта үзенчәлекле эш итүне соравыннан килә. Шуңа дәрес үрнәкләрендә әлеге өлешкә киң тукталынмады. Текст белән эш телне яхшы белмәүче балалар өчен дөрес уку һәм укыганны аңлау, гади сорауларга җавап бирүдән дә артмаска мөмкин. Ләкин шул ук сыйныфта телне яхшырак белгән баланың бөтен биремнәрне дә үтәве һәм өстәмә эш өчен дә вакыты калуы ихтимал. Текст белән эшләүнең уртак таләпләре: аңлап йөгерек уку, эчтәлеккә кагылышлы сорауларга җавап бирү, аның нәрсә турында булуын һәм эчтәлеген үз сүзләре белән әйтеп бирү, нәтиҗә ясау, сүз байлыгын арттыру.

Нәтиҗә ясау һәрвакыт баланың тормыш тәҗрибәсе белән бәйле булганда яхшы. Укучы әдәби әсәр эчендәге вакыйга һәм кичерешләрне үз күңеле аша үткәрә алырга тиеш. Бала бер генә мизгелгә шул әсәрдәге тормыш белән яшәп алганда гына, укуның файдасы булачак һәм шәхескә юнәлтелгән максатка хезмәт итәчәк. Хисләрне кузгата алмаган укуның нәтиҗәсе балага хәреф тануы һәм укый белгәне өчен билге куюдан артмый. Беренче сыйныф дәреслеге укучыга иң таныш хисләр белән эш итә: ярату – яратмау, ышану – ышанмау, ошау – ошамау, кызгану, ачулану, үпкәләү. Сорауның эчендә үк җавап та булу яки сайлап алу мөмкинлеге укучыда ышаныч тудыра. Теоретик төшенчә буларак өйрәнмәсә дә, укучы халык авыз иҗаты, мәкальләр, тел-сурәтләү чаралары белән таныша. Аралашу әдәбе, үз-үзен тоту кагыйдәләрен үзләштерә. Дәреслек тулысы белән баланың үз тиңдәшләре белән аралашуына, алар белән бер мохиттә яшәвенә юл ача. Моңа дәреслек геройларының ярдәме зур.

Ничек кенә булса да, белем һәм тәрбия бирүче кеше – Укытучы, аның һәр сүзе, хәрәкәте, карашы, гамәлләре тәрбияли. Башлангыч сыйныф укучысында «Белергә теләмим» дигән фикер юк. Бары аның күңелендә «Мин булдыра алмыйм» дигән уй тумаска тиеш. Шуның өчен дәреснең бер генә мизгеле дә аның күңелен кайтарырлык яисә теләген сүндерерлек булмасын. Бу – укытучыдан белем, теләк, көч таләп итә, ә тәҗрибә вакыт белән килә.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Тема:** Әйдәгез, танышабыз!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапны ярату, китап уку, туган телдә аралашу теләге туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тамга-символик чараларны куллану; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – әдәби уку предметының эчтәлеген аңлау, дәреслекнең шартлы тамгаларын хәтердә калдыру; Җәүдәт Дәрзаманның «Тискәре хәрефләр» шигыренең эчтәлеген тикшерү, аның нигезендә сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

– Хәерле көн, балалар! Бүген дәрескә нинди кәеф белән килдегез?

Мәктәпкә килгән көннән алып туган телебездә хәреф танырга өйрәткән иң беренче китабыгыз – Әлифба – бүген өегездә калды. Киләчәктә белемле булу өчен, ул сезне иң кирәклесенә – укырга өйрәтте. Сез хәзер, беркемнән дә ярдәм сорамыйча, теләгән китабыгыз белән үзегез таныша, аның белән икәүдән-икәү генә

серләшә аласыз. Ә Әлифба сезнең өчен иң кадерле китап булып калсын. Үсеп, белемле кеше булгач та, Әлифба мәктәп бусагасын атлап кергән беренче көнегезне, менә бүген янәшәгездә булган сыйныфташларыгызны, шушы матур сыйныф бүлмәсен исегезгә төшереп торыр. Әйдәгез, бу мизгелләр матур истәлек булып калсын өчен, бер-беребезгә елмаябыз. Һәр нәрсәне истә калдырырлык итеп, тирә-ягыбызга карап чыгабыз. Сезнең кулыгызда бүген яңа дәреслек. Дәреслегегезне кулыгызга алыгыз да, аның тышлыгындагы рәсемнәргә карагыз.

Сез анда кемнәрне күрәсез? Әйе, анда нәкъ сезнең кебек укучы балалар.

Сезнең алар белән танышасыгыз киләме? Әйдәгез, танышабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслектәге геройларның диалогы белән танышу.

Биредә видеодәресне кушарга мөмкин, шул вакытта танышу кызыклы һәм җанлы булачак. Ахырдан: «Балалар, менә бүген безнең дусларыбыз артты. «Әдәби уку» китабы безне яңа кызыклы шигырьләр, хикәяләр белән таныштырачак икән. Ә Алмаз, Гөлназ һәм Нур – бик тырыш балалар, китап укырга, күп белергә яраталар», – дип нәтиҗә ясыйбыз.

Бу урында Гөлназның китапханәсенә игътибарны юнәлтеп, китап уку, мәктәп китапханәсе белән ничек эшләү хакында сөйләшергә мөмкин. (Бу – укучыларның татар телендә әңгәмәгә әзерлекле булуларына бәйле.)

Тырыш кеше, тырышлыкның әһәмияте турында сөйләшү кирәк. Әлеге әңгәмә татар мәктәпләрендә укучылар (предметны тирәнтен өйрәнүчеләр) белән үткәрелә, рус мәктәпләрендә (база өлешен генә өйрәнүчеләргә) белем алучы балаларга укытучы үзе аңлата. Нәтиҗә ясап, дәрестә нәрсә турында сүз барачагы ачыклана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Электрон дәреслектә Җәүдәт Дәрзаманның аудиоязма форматында бирелгән «Тискәре хәрефләр» шигыре тыңлана. Аны

видеодәрестә дә күрсәтергә, тыңлатырга мөмкин. Сүзлек белән танышу һәм балалар төшенмәгән башка сүзләр дә булса аңлатырга кирәк. Укучы аңламаган сүзне башта сүзлектән карарга, аннан тапмаса сорарга өйрәнергә тиеш. Сорауларга җавап биргәнче, шигырьне балалардан укыту зарур. Һәр дәрестә уку тизлегенә ярдәм итәрлек бирем булырга тиеш.

Башта китаптагы сораулар ярдәмендә фикерләшү характерында җаваплар тыңлана. Ахырдан, балалар белән бергәләп, сорауларга җавап бирелә.

Алга таба, укытучы «Хөрмәтле Дәреслек»не белдергән шартлы тамгага игътибар иттерә һәм балаларны әңгәмәгә алып чыга. Алар үзләре турында сөйлиләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әңгәмә үткәрелә:

– Балалар, менә безнең яңа дусларыбыз – Хөрмәтле Дәреслек, Алмаз, Гөлназ һәм Нур: «Без бергә һәм бердәм», – диләр. Без дә бердәм һәм татумы?

Бүгеннән Хөрмәтле Дәреслек, Алмаз, Гөлназ һәм Нур безнең белән бергә булып, ярдәмләшеп торырлар. Ә аларның ярдәмен без дәреслектәге төрле тамгалардан танып алырбыз. Карагыз әле, сез дәреслекнең 8 нче битендә нинди тамгалар күрәсез?

Укытучы дәреслекнең шартлы тамгалары белән таныштыра. «Сабантуй бүләге»нә игътибарны юнәлтеп, аның укучылар өчен һәрвакыт кирәк булачак акыллы киңәшләрдән торачагын, бу мәгълүматны хәтергә салып куюның бик тә файдалы икәнлеген искәртә. Укучылар дәреслекнең шартлы билгеләрен бер тапкыр карауда гына хәтерләрендә калдыра алмый, шуңа күрә аларга һәр дәрестә игътибар итәргә, тамганың нәрсә белдерүен кабатлап торырга кирәк булачак. Әгәр теләсә, укытучы дәреслек геройларының сүзләрен дә һәр дәрестә аерым бер укучыга йөкләтә ала. Бу очракта баланың дәрестә игътибары, җаваплылыгы арта, үзен оештыручы ролендә тоя. Ул аның шәхес буларак формалашуында әһәмиятле роль уйный.

Укучылар, «Сабантуй бүләге»ндәге «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» мәкаленә нигезләнеп, тырышлык булганда кеше башкарып чыга алмаслык эш юклыгын аңларга тиешләр. Укытучы шуңа нигезләнеп нәтиҗә ясый. Тырыш, тату, бердәм булу кешене бизи, ә ис китмәү, җебек булу кебек тискәре сыйфатлар ямьсез итә дип аңлата ала. Бу дәрестә укучы әлеге сүзләрнең берничәсен генә булса да сөйләменә кертә алырлык дәрәҗәдә үзләштерсә, бик яхшы.

Татар мәктәпләрендә «Әлифба турында әкият» тә укыла. «Балалар, Алмаз узган дәрестә безгә төрле шигырьләр, хикәяләр алып киләм дигән иде. Бу дәрескә нәрсә алып килде икән?» – дип, дәреслектәге Алмаз репликасы укыла. Алга таба «Әлифба турында әкият» белән танышыла. Китапның 12 нче битендәге рәсемгә нигезләнеп, укучылар әкияттәге хәрефләр турында сөйли алалар.

Әлифбаның хәрефләрнең йорты, анда һәр хәрефнең үз урыны булуы әйтелә. Әлифбадагы хәрефләрдән сүзләр ясалуы, сүзләр ярдәмендә аралашуыбызны аңлатабыз. Һәр халыкның үз әлифбасы була. Мәсәлән, рус әлифбасында «ә» хәрефе юк. Ә татарча «ә» хәрефе безнең өчен иң кадерле *әни, әти, әби* сүзләрен язарга кирәк дип күрсәтергә мөмкин.

«Әгәр хәрефләр шулай таралып, төрле җирдә йөрсәләр, чыннан да, авыр булыр иде. Менә хәрефләре югалган сүзләргә тиешле хәрефләрен куеп укыйк әле», – дип, китапның 13 нче битендәге сүзләрдә югалган хәрефләрне тапкач, сүзләрне дөрес итеп укыйлар.

Балаларның бу кошларны, чәчәкләрне белү-белмәүләрен сорашып, алар турында кирәкле мәгълүмат биреп, әңгәмә үткәргән очракта, укучыларның сөйләме байый, мәгълүматы арта.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Мәктәптә беренче көн.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – һәркемнең үзе өчен бик якын кыйммәтләр булган кебек, һәр халыкның да кадерләп саклый торган мирасы булуын аңлау. Хәтер кешенең иң зур байлыгы икәнлегенә төшенү. Башкалар хисен үзеңнеке кебек кабул итә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; мәгълүмат табу; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Мөхәммәт Мәһдиевнең «Мәктәптә беренче көн» хикәясенең эчтәлеген аңлау, аның нигезендә сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик, «Сабантуй» журналлары.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Сүзне түбәндәгечә башлый алабыз:

– Беләсезме, балалар, безнең дусларыбыз кичә Татарстанның Арча районында урнашкан Әлифба музеенда булганнар. Әйдәгез, аларны тыңлап карыйк әле.

Дәреслектәге Гөлназ, Алмаз, Нурның репликалары белән танышып, бу музей турында рәсемнәр ярдәмендә әңгәмә үткәрәбез. http://protatarstan.ru/alifba-muzee/ укытучы өстәмә мәгълүматны биредән таба ала, укучылар өчен музей күренешеннән

фоторәсемнәр дә бар. Шулай ук, тагын бер вариант буларак, өлешләп видеодәресне күрсәтә алабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алга таба укытучы:

– Музей нинди урын ул?

– Нинди әйберләр кадерле була?

– Ни өчен бу әйберләрне музейда саклыйлар? – кебек сораулар белән әңгәмә үткәрә. (Үткәнне аңларга, кем булуыңны белергә ярдәм итә. Хәтерсез кеше – бәхетсез кеше, дигән нәтиҗәгә килене. Бу бик гади итеп, балаларча мисаллар белән булса яхшы.)

Укучылар дәреслекнең музей турындагы аңлатмасы белән танышалар, Алмаз һәм Гөлназ репликалары аша мәктәпкә беренче тапкыр килүләрен хәтергә төшерәләр. Әңгәмә коралар. Кеше хәтере бик гади истәлекләрдән алып (мәктәптәге беренче көн) зур тарихи хәлләргә (Әлифба музее – төрле халыкларның язу тарихы) кадәр сыйдыра ала, дигән нәтиҗә чыгу яхшы. Алмаз репликасын укыганчы:

– Алмаз безгә бүгенге дәрескә бер хикәя алып килгән. Ул хикәя нәрсә турында булыр икән? – дип, укучыларга дәреснең темасын әйттерәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алмаз репликасы белән танышкач, хикәяне укыганчы, укытучы китаптагы рәсемгә игътибар иттереп, аның турында сөйләшү үткәрә ала.

Бу очракта түбәндәге сораулар ярдәм итәр:

– Рәсемдә елның кайсы вакыты?
– Көн нинди?
– Рәсемдә кемнәрне күрәсез? Аларның кәефе ничек?
– Арттарак урнашкан бина мәктәп булырга мөмкинме?
– Әтисе һәм улы мәктәптән кайтып киләләр дип уйлый алабызмы?

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Мәктәптә беренче көн» хикәясенең электрон дәреслектәге аудиоязмасын тыңлатырга була. Сүзлек

белән эш һәм сорауларга җавап бирү үз эзлеклегендә үтәлә. Балаларның әзерлегенә карап, ***хәйләкәр*** сүзенең мәгънәсе төрле икәнлеген аңлатырга була. Хәйләкәрлек, башкаларга начарлык буларак юнәлтелмәгәндә, *шаян, мут* мәгънәсенә якын, ә усаллыкка, явызлыкка ишарә иткәндә, ул *астыртын, мәкерле* мәгънәсенә туры килә.

5, 6–8 нче сораулар укучыга хикәя эчтәлеген үз күңеле аша үткәрергә ярдәм итә, дәрестә ирекле әңгәмәгә юл ача. Укучының үзе яраткан мультфильмы турында сөйләү, Искәндәрнең хисләрен үзенеке кебек кичерү хисне тану, бәяләү мөмкинлеге бирә. Әдәби әсәр хисләр аша кабул ителә, шуның өчен укучы әсәр героеның хисен үзе аша үткәреп кабул итәргә өйрәнергә тиеш, бу – һәр дәрес өчен бик әһәмиятле таләп.

«Мәктәптә беренче көн» хикәясендәге Искәндәр кичерешләрен үз күңелләре аша үткәрергә укучыларга Алмаз сораулары ярдәм итәчәк. Гөлназ һәм Нур репликасы алдагы этапка күпер салу өчен кирәк.

Алга таба Хөрмәтле Дәреслек укучыларны «Сабантуй» журналы белән таныштыра. Укытучы «Сабантуй» журналын һәр партага тарата ала (әгәр мәктәп китапханәсендә, я кабинетта саклanса). Укучылар журнал белән танышып чыккач, бу басма турында бергәләп әңгәмә уздырырга мөмкин. Журналның айга бер чыгуы, эчтәлегенең, рәсемнәренең төрлелеге, анда укучыларның яшьтәшләре булган балаларның шигырьләре, рәсемнәре, мәктәп тормышыннан язмалар булуына игътибар ителә. Укучыларга бу журналга язылырга мөмкин икәнлеге әйтелә.

Татар мәктәпләрендә Алмаз һәм Гөлназ тәкъдим иткән биремнәр дә үтәлә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Без бүген укыган хикәя ничек атала? Бу хикәя кем турында?» кебек хикәянең эчтәлеген аңлауга, ачыклауга корылган сораулар һәм хәтердә озак саклана торган вакыйгалар, *хәтер, истәлек* сүзләренең мәгънәсен аңлап калырга ярдәм иткән сораулар белән белемнәр ныгытыла.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Өйрәтәләр мәктәпләрдә.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – укый белү – белем алуның иң төп нигезе булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен белдерү, әйтелгән фикерләрдән иң әһәмиятлесен сайлап нәтиҗә ясый алу.

*Предмет нәтиҗәләр* – Муса Җәлилнең «Беренче дәрес» шигыренең эчтәлеген аңлау, аңа кагылышлы сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** М. Җәлилнең «Беренче дәрес» китабы, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы сүзне алдагы дәрестәге иҗат эше турында искә төшерүдән башлый ала. «Иҗат итү өчен, аның серләрен белергә кирәк, – ди ул. – Ә безнең дусларыбыз нәрсә турында сөйләшә икән? Әйдәгез, аларны тыңлыйк әле», – дип, персонажларның диалогы белән таныштыра.

**III. Уку мәсьәләсен кую.** Алмаз тәкъдим иткән табышмакның җавапларын табу ярдәмендә бу дәрестә шигырь турында сүз ба-

рачагы билгеләнә һәм иң элек «Нәрсә соң ул шигырь?» дигән сорау куела (Алмаз репликасы).

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектәге
Чәчәкләр тотып к у л г а,
Без чыктык матур ю л г а.
Һәркем белә, ә л б ә т т ә,
Без барабыз м ә к т ә п к ә! – дигән юллар укыла. «Укучылар, бу шигырьме? Ә шигырь нинди була?» кебек сорауларга җаваплар белән балаларның фикере әйттерелә.

Нурның күп белүен истә тотып, аның фикерен дә тыңлыйбыз. Төп нәтиҗәне, әлбәттә, Хөрмәтле Дәреслек ясый. Шигырь турындагы төшенчәне укучылар Дәреслек репликасында тәкъдим ителгәнчә хәтерләрендә калдырырга тиеш. Укытучы шигырьнең тышкы формасына (аерым юллардан торуы, җөмләнең бер юлда гына тәмамланмавы) ритмик яңгырашын искәртә ала. Шигырьнең видеоязмадагы укылышына игътибар итү аша моны тагын да тирәнәйтергә мөмкин.

«Менә хәзер шигырьнең ничек барлыкка килү серен дә белдек, димәк, сез үзегез дә «Сабантуй» журналына шигырь яза аласыз», – дип, бу өлешкә нәтиҗә ясарга була.

Алга таба Алмаз Муса Җәлилнең «Беренче дәрес» шигырен тәкъдим итә. Шигырьне уку, сүзлек белән эш, сорауларга җавап бирү теманы үзләштерүгә ярдәм итә. «Йөгерек уку ничек була? «Нинди зур бәхет, нинди ү з г ә р е ш!» дигән юлларда нәрсә турында әйтелә? Син йөгерек укый аласыңмы? сораулары ярдәмендә шигырьдәге вакыйганы балаларның үз тормышлары белән бәйләп кабул итүгә нигезләнсәк әйбәт. Һәр әсәрнең эчтәлегендә бала үз тормышына якын якларны таба алса, шуның белән тәңгәллек туса, яңалык та җиңелрәк үзләштерелә, хәтерендә дә ныграк саклана.

Шигырьнең авторына игътибар итеп, Муса Җәлилнең кем икәнлеген балалардан кызыксынып, беркадәр мәгълүмат бирергә

була (Муса Җәлилнең туган көне – 15 февраль, бәлки, дәрес шул датага якын булыр).

5–7 нче сорауларны электрон тактада эшләү укучы өчен җиңеллек тудырачак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Шигырьне без ничек таныйбыз?», «Рифмалашкан сүзләр нинди сүзләр ул?» кебек сораулар теманы ныгытырга ярдәм итә.

Укый белүнең кешегә нинди мөмкинлекләр ачуы, китап укуның белем алуда әһәмияте (бөтен фәннәрне үзләштерү өчен йөгерек уку, укыганны аңлау кирәклеге) турында сөйләшү үткәрергә була.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Иң татлы тел – туган тел

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган телгә мәхәббәт хисенә төшенү, башка телләр өйрәнү теләге туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәйхи Маннурның «Яхшы бел» шигыренең эчтәлегенә төшенү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру. Табышмак әйтү яки кечкенә шигырь уку дәрестә өйрәнеләчәк темага карата кызыксыну уятачак, билгеле бер эмоциональ фон тудырачак.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта алдагы дәрестә үтелгәннәр искә төшерелә. Укучылар белән «Өйрәтәләр мәктәпләрдә» темасында өйрәнгәннәрне искә төшерү, Муса Җәлилнең «Беренче дәрес» шигырен сәнгатьле уку рәвешендә үткәрергә була. Шулай ук алдагы дәрестә үзләштерелгән *шигырь* төшенчәсен дә кабатлап алу артык булмаячак.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Биредә, темага алып кереп китү максатыннан, укытучының юнәлеш бирүче сораулары белән бергә, дәреслектәге темага кагылышлы материалны да файдаланырга мөмкин. Алмаз һәм Гөлназның сүзләре белән таныштыру дәрестә өйрәнеләчәк тема, мәсьәләне билгеле бер дәрәҗәдә аңлауга китерәчәк. Укучылар бу очракта дәрестә туган тел турында сүз барачагын авырсынмыйча әйтә алачак.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әсәр белән танышу алдыннан сүзлек эше үткәрелә.

Шәйхи Маннурның «Яхшы бел» шигыре белән танышу традицион рәвештә укытучының сәнгатьле итеп укуы яки аудиоязмадан әсәрне тыңлау рәвешендә башкарыла. Бу вакытта ук шигырьнең мәгънәсенә төшенү процессы башлана. Алга таба, шигырьнең мәгънәсен тулысынча аңлагач, берничә укучыдан аны укуны оештыра алабыз.

Алга таба укучылар шигырьдән алган беренче тәэсирләре белән уртаклашалар. Бу вакытта ук укучы туган теле булган татар телен, шулай ук рус телен дә яхшы белергә кирәклеген аңларга-

төшенергә тиеш. Сорауларга җавап бирү шигырь эчтәлеген, аның төп фикерен аңларга ярдәм итә.

Шигырьдә кулланылган *затлы* сүзенә аерым игътибар биреп, мәгънәсенә төшенү өчен, дәреслектәге Нур аңлатмасын файдаланырга була.

Укучыларга тәкъдим ителә торган сораулар рус һәм татар телләренең әһәмиятен билгеләргә булыша. Монда укучыга үз гаиләләрендәге хәл белән чагыштырып карау мөмкинлеге бирелә. Телнең кешеләрне дуслаштыруы турындагы сорау бирсәк, ул укучыны уйлануга этәрә.

Татар мәктәпләрендә укучылар өчен шигырьдә очраган аерым гыйбарәләрнең мәгънәләрен ачыклау файдалы булачак. «Үз теле» дигәндә авторның кайсы телне күздә тотуын ачыклау аша бала бу телне ни өчен онытмаска кирәклегенә төшенә.

Шигырьне ятларга тәкъдим итәбез.

Нур репликасы Халыкара Туган тел көне турында мәгълүмат бирергә һәм бәйрәмнәр турында сөйләшүгә алып чыгарга ярдәм итә.

«Ни өчен Туган тел көне халыкара бәйрәм икән?» дигән сорауга җавап эзләнелә.

Туган телен кадерләгән халык кадерле була. Үз телен, үз милли үзенчәлекләрен саклаган халыкны башкалар да таный, хөрмәт итә. Теле, милли үзенчәлекләре булмаса, бу халык онытыла, аның барлыгын, кем икәнен дә белмиләр.

– Татар телен кайларда ишетәсең? – дип сорыйбыз. (Укучы татар телевидениесе, театрларыбыз, кино булуын ишетеп калсын.)

– Татар телендә газета, журнал, китаплар күргәнең бармы? (Җавапларны укытучы тулыландыра.)

Татар телендә белем бирә торган мәктәпләр барлыгын да әйтү дөрес булыр.

Телнең кулланылыш даирәсенең киң, милли гореф-гадәтләребезнең бай булуын әйтеп нәтиҗә ясала.

Алмазның соравына җавап биреп, бәйрәмнәрне искә төшерәбез. Укытучы гаилә бәйрәме (туган көн), аерым халыкларның бәйрәмнәре (төрки халыкларда – Нәүрүз, Сабантуй) ил күләмен-

дәге бәйрәмнәр (Җиңү көне) һәм халыкара бәйрәмнәр (8 Март) булуын искәртә ала.

Бу төшенчәләргә аңлатма биреп китәргә кирәк. Бигрәк тә халыкара бәйрәмнең Җир шарында яшәүче барлык халыклар өчен уртак булуы ассызыклана.

Укучының бәйрәм турында күзаллавы ниндилеген сораулар аша ачыкларга да мөмкин. Ул рәсем турында сөйләү өчен юл ача.

Китаптагы Сабантуй аланы, Туган көн бәйрәме рәсемнәре турында киңрәк сөйләшү үткәрергә кирәк. Укучы рәсемдәге матурлыкны, милли үзенчәлекне күрергә өйрәнсен иде. Мәсәлән, чиләк-көянтә, өс киемнәре, бизәкләрдәге милли үзенчәлекләр, гаиләдә табын әдәпләре һ.б.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу өлешне дәреслектәге «Иң татлы тел – туган тел» дигән мәкаль белән эшләү рәвешендә оештырырга мөмкин. Укучылар *татлы тел* гыйбарәсен ничек аңлауларын әйтәләр, укытучыга шуның аша туган телнең кеше өчен бик кадерле булуын төшендерергә кирәк булачак.

Тирәнтен өйрәнү өлешендә, теманы үстереп, укучыларга телләр белүнең әһәмиятен билгеләү максатыннан, әңгәмә үткәреп була.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар дәрескә нәтиҗә ясыйлар. Дәреснең төп фикерен кабат күңелдә барлап, аның әһәмиятен билгелиләр.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Туган җир якын, туган тел якын

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган җирнең кадерен белү, *туган җир*, *туган тел* төшенчәләренең бәйләнешен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – максат формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Хәсән Туфанның «Казан» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Шәйхи Маннурның үткән дәрестә өйрәнелгән «Яхшы бел» шигырен яттан сөйләү итеп яки шигырь эчтәлеге белән бәйле сорауларга җавап бирү рәвешендә оештырырга була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен дәреслектә бирелгән *туган* сүзенең мәгънәсенә төшенү, аның башка сүзләр белән янәшә куллану очраклары аша билгеләтергә мөмкин. Бу сүзнең Нур тәкъдим иткән синонимнарын күрсәтү дә уңышлы булачак.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әлеге этапта *туган ил, туган җир, туган як* төшенчәләре турында сөйләшүне дәреслек персонажларының әңгәмәсе һәм укучыларга биргән сораулары ярдәмендә үткәрергә мөмкин. Бала бу очракта әлеге төшенчәләрне, киңрәк мәгънәдә файдаланып, илебез Россия һәм туган җиребез Татарстан белән бәйле аңлый. Бирелә туган җир турындагы шигырь-табышмакка игътибар итү дә урынлы була.

Татарстан Республикасының башкаласы Казан шәһәренә аерым тукталу күздә тотыла. Бу уңайдан өйрәнү өчен Хәсән Туфанның «Казан» шигыре тәкъдим ителә.

Сүзлек эшен үткәргәч һәм балаларга махсус аңлатма таләп иткән *кыйбла* сүзе белән эшләгәннән соң, шигырьне укуга күчәбез. Ул – әсәр өстендә эшләүне, сорауларга җавап бирүне күздә тота. Шигырьдән соң урын алган сораулар аның эчтәлеген ачыклауга ярдәм итәчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта төрле эш төрләрен кулланып була. Ул – темага кагылышлы әңгәмә яки дәреслектә бирелгән рәсемнәр белән эшләү рәвешен дә алырга мөмкин. Ахырдан Сабантуй күчтәнәче булган Казан турында риваять белән танышу укучыларның танып белү мөмкинлекләрен тагын да киңәйтә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Рәсем дәресендә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – матурлыкны күрә белүнең әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, рәсемгә карап фикер йөртә белү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә алу.

*Предмет нәтиҗәләр* – Бари Рәхмәтнең «Рәсемнәр ясыйбыз» (татар мәктәпләрендә Нәҗип Мадьяровның «Салават күпере» әсәре дә) шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар

телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның мәктәптә нинди фәнне яратулары турында әңгәмә оештырырга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Өйрәнеләчәк темага укучыларның рәсем ясарга яратулары турында сөйләшү аша килеп була. Укучылар дәрестә рәсем турында сүз барачагын аңларга һәм әйтергә тиешләр.

Шуннан соң дәреслектәге Гөлназ сүзләренә тукталып һәм Алмаз буяу алып кайтканчы, балаларның Бари Рәхмәтнең «Рәсемнәр ясыйбыз» шигырен укыячаклары хәбәр ителә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бари Рәхмәтнең «Рәсемнәр ясыйбыз» шигырен уку. Укытучыдан соң берничә яхшы укучы дәвам итә. Шигырьдән алган тәэсирләрен уртаклашу шигырьнең эчтәлеген төшенүгә әзерлек этабы булып тора. *Оста* сүзенең шигырьдә нинди мәгънәдә килүенә тукталабыз. Теләге булган берничә укучыдан шигырьне тагын укытабыз.

Дәреслектә бирелгән иллюстрация белән сөйләм үстерүгә юнәлтелгән әңгәмә оештыру бик отышлы. Бу эш укучыларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыруга хезмәт итәчәк.

Дәреслектә бирелгән сорауларга нигезләнеп, җаваплар алына. Бу урында укучыларның рәсем ясаган вакытларындагы тәҗрибә-

гә таяну отышлы. Әлеге шөгыльләргә ничек карауларын ачыклау да тәнкыйди фикерләүләрен үстерүгә булышлык итәчәк.

Татар мәктәпләрендә Нәҗип Мадьяровның «Салават күпере» әсәре дә өйрәнелә. Дәреснең бу өлеше салават күперендәге төсләр, аның ничек барлыкка килүе турында да сөйләшүгә этәрә. Димәк, ирекле әңгәмәгә алып чыга.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә дәреслектәге материалны кулланабыз. Теманың икенче өлешендәге сорау-биремнәр, аерым алганда төсләрне барлау, табышмакны укып аңа җавапны табу укучыларга кызыклы булачак. Алмазның соравына җавап бирү коммуникатив максатны күздә тота. Укучыларның үзләре теләгән темага рәсем ясаулары бу этапта әңгәмәгә кушылырга этәргеч бирәчәк.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Якты йөзле укытучым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – мәктәптә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү, укытучыны хөрмәт итәргә өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; иҗади күзаллау; күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – укылган текстның эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәреслек геройлары Гөлназ, Нур һәм Алмазның әңгәмәсе мәктәп, укытучы, мәктәптәге тәртипләр турында сөйләшү оештырырга ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Гөлназ репликасы уку мәсьәләсен куярга булыша.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Гөлназ куйган сораугa җавап эзләүне төрлечә башларга мөмкин: дәреслектәге рәсемгә нигезләнеп, укучыларның фаразларын тыңларга, малайның парта астында утырганда ниләр кичерүе турында уйланырга. «Ул дөрес эшлиме?» кебек сорауга җавап эзләргә һ. б. Виктор Голявкинның «Парта астында» хикәясен уку, сүзлек белән эш, сорауларга җаваплар бирүне укытучы үзе теләгәнчә оештыра. Ахырдан укучыларның хикәяне укыганчы әйтелгән фикерләре чагыштырыла. Мәктәптә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре искә төшерелә. Мәктәптә үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтүче дә, белем бирүче дә – укытучы, аның сүзен һәрвакыт тыңларга һәм үтәргә кирәклеген искәртеп нәтиҗә ясала.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

Хикәянең эчтәлеген искә төшерү, малайның парта астында утыруының сәбәбен әйтү; укытучы җавабына нигезләнеп, бу малайның тәртибе турында нәтиҗә ясау; мәктәптә үз-үзеңне тоту, укытучы сүзенә һәрвакыт игътибарлы булу турында сөйләшү.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Мәктәп – белем йорты (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – мәктәптә укуның әһәмиятен аңлау, мәктәпкә хөрмәт хисе уяну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя, әңгәмәдә катнашу, гомумиләштереп нәтиҗә ясау, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Мәктәп» темасында өйрәнелгәннәрне гомумиләштерә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

Дәреснең темасы булган «Мәктәп – белем йорты» мәкален аңлату аша сөйләшү үткәрергә мөмкин. Алдагы темаларда өйрәнгән әсәрләргә таянып, фикерләрне дәлилләтәбез.

**II. Уку мәсьәләсе кую.**

Теманың башында Хөрмәтле Дәреслекнең бирелгән сүзләренә, сорауларына нигезләнеп, укучылар әлеге дәрестә дә мәктәп турында сөйләшү булачагын фаразлыйлар. Укытучы дәрестә мәк-

тәп тормышы турындагы зур тема кысаларында үткәннәргә йомгак ясалуы турында хәбәр итә.

**III. Белемнәрне ныгыту.**

Өйрәнгәннәрне искә төшерү, гомумиләштереп кабатлау уен рәвешендә тәкъдим ителә. Уен-йөреш бу очракта укучыларга бик кызыклы булачак. Алар цифрлар астында бирелгән сорауларга эзлекле рәвештә адымлап җавап бирәләр, җавапларның беренче хәрефләрен аста бирелгән буш шакмакларга тутырып баралар. Анда МӘКТӘБЕМ сүзе төзелергә тиеш. «Синең өчен мәктәп нәрсә ул?» – дип сорап, укучыларның бу турыда карашларын беләбез.

Дәреслек персонажларының мәктәп хакында фикерләрен укыту дәрестә мәктәп турында әйтелгәннәргә дәлил-йомгак булып тора. Аларның киңәшләрен тотып, мәктәпнең әһәмияте тагын бер кат ассызыклана.

Татар мәктәпләрендә Фоат Садриевның «Тургай мәктәпкә бара» хикәясе өйрәнелә. Хикәяне укыгач, сүзлек эше, сорауларга җавап бирү күздә тотыла. Укучылардан мәктәптәге тәртипләргә ничек күнегүләре турында сорашу мөмкин.

Гөлназ китапханәсенә кергән китаплар белән танышу, реклама ясау алга таба укучыларда аларны алып уку теләген уятырга тиеш.

**IV. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Безнең гаиләбез

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – гаилә, аның әһәмияте турында белү, йорт хайваннарына мәрхәмәтле булу кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә һәм диалог төзүдә катнашу.

*Предмет нәтиҗәләр* – Габдулла Тукайның «Безнең гаилә» шигыренең (татар мәктәпләрендә Нәҗип Мадьяровның «Булышабыз» шигыре дә) эчтәлеген белү, аның нигезендә сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Бу дәрестә «Минем гаиләм» исеме астында зур теманы өйрәнү башлана. Дәрес башында Алмазның табышмагына җавап эзләнә. Хөрмәтле Дәреслекнең укучыларга мөрәҗәгате, *гаилә* төшенчәсен ничек аңлаулары турында дәреслек персонажларыннан сораштыру укучыларны бу турыда сөйләшүгә тартачак.

**III. Уку мәсьәләсе кую.**

Актуальләштерү этабында эшләнгәннәр укучыга уку мәсьәләсен куюда булышлык итә. Алар дәрестә сүзнең нәрсә турында барачагын авырсынмыйча әйтә алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу этапта Габдулла Тукайның «Безнең гаилә» шигыре өйрәнелә. Шигырьдән соң бирелгән сорауларга җавап бирү аның эчтәлеген ачыкларга ярдәм итә. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә өстәмә ике сорауга җавап бирү каралган. Бу сорауларны база өлешен өйрәнүчеләргә дә тәкъдим итеп була. Укучыларга төп уку материалын җиткерү өчен, видеодәресне дә кулланырга мөмкин.

Алга таба дәреслектә урын алган «Тату гаилә – бәхетле гаилә» мәкале белән эшләү күздә тотыла. Шулай ук йорттагы кече дусларыбыздан мәчеләр, этләр һәм башка җан ияләре турында сөйләшү дәресне җанландырып җибәрәчәк.

Программада әлеге шигырьне ятлау каралган.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Предметны тирәнтен өйрәнүче укучыларның үз гаиләләре турында сөйләшү – гаиләдә ничә кеше, кемнәр барлыгы, алар белән мөнәсәбәтләр хакында әңгәмә – үз гаиләләре белән таныштыру мөмкинлеген бирү аларның коммуникатив күнекмәләрен үстерүгә дә хезмәт итә.

Коммуникатив күнекмәләрне үстерүгә шулай ук гаилә белән ял көннәрен үткәрү турында диалоглар төзү дә ярдәм итә. Моны дәреслектә бирелгән үрнәккә нигезләнеп эшләргә мөмкин. Әлеге эш төре рус телендә белем бирүче оешмаларда укучылар өчен аеруча файдалы булачак.

Татар мәктәпләрендә Нәҗип Мадьяровның «Булышабыз» шигыре дә өйрәнелә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Әниемнең әнисе әбием була минем

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – өлкәннәрне, дәү әни һәм дәү әтиләрне ярата, хөрмәт итә, аларның күңелен күрә, сөендерә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; иҗади күзаллау, күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәүкәт Галиевнең «Дәү әнигә күчтәнәч» шигыренең (татар мәктәпләрендә Абдулла Алишның «Әбиләрдә кунакта» хикәясенең дә) эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә алу, синоним һәм антоним төшенчәсен белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар белән алдагы дәресләрдәге сөйләшүләргә нигезләнеп, гаилә темасын дәвам итәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куярга дәреслек геройларының биреме (ребус) һәм әңгәмәләре, ачкыч сүзләр ярдәм итә. Укучылар бу дәреснең иң якын кешеләребез – дәү әниләр, дәү әтиләр турында булуын әйтеп бирә ала.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алмаз репликасы аша Шәүкәт Галиевнең «Дәү әнигә күчтәнәч» шигырен өйрәнүгә күчелә. Бу өлештә видеороликны кулланып эшләү уңышлы булыр.

Татар мәктәпләрендә Абдулла Алишның «Әбиләрдә кунакта» хикәясе дә өйрәнелә. Укытучы еракта яшәгән дәү әни, дәү әтиләребезгә, еш кайта алмаганда, күчтәнәчне тартмага тутырып җибәрү кулай булса, якында яшәгән дәү әниләребез янына үзебез барып килүнең яхшырак икәнен әйтә. Бу урында күчтәнәчтән бигрәк искә алу, хөрмәт итү, ихтирам билгесенең әһәмиятлерәк булуы искәртелә.

Нур репликасы ярдәмендә Абдулла Алишның «Әбиләрдә кунакта» хикәясен укуга күчелә. Хикәяне өйрәнү эшен укытучы

үзе теләгән тәртип белән оештыра. Бу дәрестә укучылар *синоним* һәм *антоним* төшенчәләрен дә үзләштерә. Сөйләмдәге әһәмияте, әдәби вазифалары зур булганлыктан, укучылар аларны таный һәм куллана белергә өйрәнүләре яхшы.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

Укылган әсәрнең эчтәлегенә караган, укучы күңелендә аның нинди хисләр, теләкләр уятуын ачыкларга ярдәм иткән сораулар ярдәмендә белемнәр ныгытыла. Шуның аша өлкәннәрне хөрмәт итү, аларны сөендерүнең әһәмияте турында сөйләшү үткәреп, нәтиҗә ясала.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Барысын да яратам

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – гаиләдәгеләрне ярату хисенең ихласлыгын аңлау, якыннарыңа һәрвакыт ышану, таяну мөмкин икәнен белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, нәтиҗәләр ясау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Разил Вәливнең «Барысын да яратам» шигыренең, (Гүзәл Әдһәмнең «Кызыл муенса» хикәясенең) эчтәлеген аңлау, төп фикерен билгели һәм сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдул-

лина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

Җиһазлау: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар белән гаиләләрендә кемнәр булуы, бергәләп нинди эшләр эшләүләре, кая барулары, кемне ныграк яратулары, ни өчен шулай икәнлеге турында сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куйганда, Алмаз тәкъдим иткән ребус һәм аның репликасы ярдәмгә килер.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Разил Вәливнең «Барысын да яратам» шигырен өйрәнүне видеороликка нигезләнеп дәвам итәргә мөмкин. Шигырьне тирәнтенрәк аңлауга ирешү дә кирәк. Аның баштагы өлеше яратуны бала күңеле өчен хас булганча сөйләп бирә. Бала һәркемне нәрсәдер өчен ярата кебек, әмма аның нәтиҗәсе тирәндәрәк – шигырь гаиләдәгеләрнең баланы яратуын ача. Һәркем үзенең яратуын балага төрлечә күрсәтә икән бит: әтисе киногa алып бара, әнисе тәмле ризыклар белән сыйлый, апасы, кечкенә энесе булганга, аны абыйсы янында яклый, аңа өстенлек бирә, абыйсы дәрес хәзерләргә булыша, әбисе малайлардан яклый, бабасы әкият сөйли. Бала (әсәрнең герое) гаиләдә яратуга күмелеп яши.

Нәтиҗә ясаганда, укучыларныж гаиләдәгеләрне яратуның эчкерсез, ихлас, туганлык мөнәсәбәтләренә нигезләнгәнлеген аңлый алуларына ирешү кирәк. Шигырьнең ахыргы юллары шуны раслый: әз генә аерылып тору да бала күңелендә юксыну, гаилә җылысын сагыну хисе тудыра. Ул үзе дә гаиләсендәгеләрне ихлас ярата.

Татар мәктәпләрендә Гүзәл Әдһәмнең «Кызыл муенса» хикәясе өйрәнелә. Бу әсәр дә туганлык җылысы турында. Максатына бәйле рәвештә, әсәрне өйрәнүне укытучы үзе теләгән эзлеклелектә оештыра. Нәтиҗәдә туганлык, бүләкләшү әдәпләре турында әңгәмәгә чыгыла.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

Укылган әсәрләрне истә калдыру, аның геройларына хас сыйфатларны хәтердә яңарту; гаиләдәгеләрне, туганнарыңны ихлас ярату турында әңгәмә ярдәмендә йомгак ясала.

**VI. Рефлексия.**

Укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Исемең матур, кемнәр куйган?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – халкыбыздагы исем кушу йоласы турында, балага исем кушуның җаваплылыгын белү, гаиләдә һәркемнең фикере хөрмәт ителгәнлеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, бирелгән эш тәртибеннән чыгып, тәкъдим ителгән чыганактан төгәл мәгълүматны табу; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәүдәт Дәрзаманның «Исем таптым» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр һәм Г. Ф. Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли?» китабы.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар белән аларның исемнәре, бу исемне кем тәкъдим итүе һәм ничек сайлаулары турында сорашу рәвешендә әңгәмә үткәрергә мөмкин. Дәреслек геройларының әңгәмәсе бу сөйләшүне башлап җибәрергә яки тәмамлап куярга ярдәм итә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы әңгәмәгә нигезләнеп, дәреснең темасы атала.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Гөлназ репликасы ярдәмендә Җәүдәт Дәрзаманның «Исем таптым» шигырен өйрәнүгә күчелә. Шигырьне өйрәнүне укытучы үз эзлеклелегендә оештыра ала. Укытучы дөньяга килгән яңа кешегә исем кушуның бик әһәмиятле икәнлеген, чөнки кеше бу исемне гомере буена йөрткәнлеген аңлата. Һәр милләтнең үзенә хас исем кушу йолалары булуын әйтеп үтә. Татар халкында хатын-кыз исемендә нәфислек, нәзакәтлелек, ә ир кеше исемендә ныклык, көч чагылырга тиешлеген искәртә. Гөлназ тапкан исемгә әти-әнисенең сөенүен әйтеп, гаиләдәге бердәмлек, зур эшләр хәл ителгәндә һәр кешенең фикере исәпкә алыну, үзара хөрмәт турында да аңлатып китә.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

Белемнәрне ныгыту әсәрне аңлау, аның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирүне һәм исем кушу йоласының асылын аңлап калуны тәэмин итәргә тиеш. Бу этапта Нур репликасы,

Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре ни сөйли?» китабы һәм «Сабантуй бүләге» ярдәмгә килер.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Өй әдәпләре (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – гаиләнең әһәмиятен аңлау, гаилә әгъзаларына хөрмәт белән карау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштереп нәтиҗә ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә алу.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Минем гаиләм» темасы кысаларында өйрәнелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өйдәге, гаиләдәге хәлләрне сорашып, темага алып кереп китеп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты хәбәр ителә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Теманы йомгаклау белемнәрне гомумиләштереп кабатлауга нигезләнә. Моның өчен укучыга дәреслектә бирелгән кроссвордны чишәргә тәкъдим ителә. Сораулар тема кысаларында өйрәнелгән материалга таянып төзелгән. Әлеге сорауларга җавап биреп, укучылар кроссвордтагы буш шакмакларны тутыралар. Кроссворд чишелеп беткәч, «Безнең гаилә» темасына зур булмаган хикәя төзергә дигән тәкъдим кабул ителә.

Дәрес ахырында Ризаэддин Фәхреддиннең өй әдәпләренә багышланган сүзләре белән таныштыру отышлы булачак. Һәр пунктка карата укучыларның фикерләрен тыңлап, тормыштан мисаллар белән дәлилләтергә мөмкин.

**V. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Мин урамны күзәтәм

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кошларны кайгырту зарурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; иҗади күзаллау, күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Идрис Туктарның «Җем-җем!.. Чвик…!», (татар мәктәпләрендә «Серле тартма» хикәяләренең) эчтәлегенә төшенү, алар буенча сорауларга җавап бирә белү, *хикәя* төшенчәсен аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина,

Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәреснең бу этабында дәреслектәге рәсемне кулланырга мөмкин. Аның өчен Алмаз репликасы һәм сораулар нигез була ала. Укучылар белән башваткыч та чишелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Актуальләштерү өлеше укучыларга теманы билгеләргә ярдәм итә. Алар бу дәрестә кыш һәм кошлар турында сөйләшү булачагын әйтеп бирә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе Идрис Туктарның «Җем-җем!..Чвик…!» хикәясен өйрәнүгә юл ача. Хикәя белән танышуны видеодәрес нигезендә алып бару мөмкин.

Татар мәктәпләрендә шул ук авторның «Серле тартма» хикәясе дә өйрәнелә. Дәреслектә бирелгән кроссвордны чишү әсәрне тормыш белән бәйләргә ярдәм итә.

**V. Белемнәрне ныгыту.**

Дәреснең бу өлешендә, укучыларның тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп, кышкы табигать, кошларга ярдәм итү турында сөйләшү үткәрелә. Балалардан ничек ярдәм итеп булуы, бу ярдәмнең әһәмияте турында сорашырга һәм, укылган хикәянең эчтәлеге белән бәйләп, сорауларга җаваплар бирүне оештырырга мөмкин. Дәрес материалының үзләштерелүен тикшерү өчен, сорауларны укытучы үзе әзерли яки дәреслектәге сораулардан файдалана.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Кояш, чык, болыт, кач!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кеше һәм табигатьнең үзара бик якын булуын аңлау, аны яратырга өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үз фикерен әйтә белү, белемне гамәлдә куллана алу.

*Предмет нәтиҗәләр – эндәш* төшенчәсен үзләштерү, аның авторсыз, халык иҗаты әсәре икәнен белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау**: слайд, проектор, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.** Алдагы дәрес темасына бәйләп, укытучы балалардан: «Кошларга җимлек куйганыгыз, аны күзәткәнегез бармы? Анда нинди кошлар килә? Җимлекне кайда куярга кирәк? Кешенең табигать белән дус яшәве тагын ничек чагылыш табарга мөмкин?» – дип сорый ала.

Җаваплар төрлечә булыр: кош оялары ясап кую, кыш көне урманда пошилар ашасын өчен, печән чүмәләләре калдыру, аерым

урыннарга солы, арыш салып кую һ.б. шундый җаваплар ишетелергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Темага якынаю максатыннан, укытучы: «Кешеләр табигатьне табигать-ана дип атыйлар. Бу нәрсәне аңлата икән?» – дип сорый.

Шулай ук: «Кешенең табигать белән бәйләнеше аның сөйләмендә, төрле уеннарда чагылыш таба алырмы икән?» – дигән сорауны бирә ала.

Җаваплар тыңлана һәм кешенең үзен табигать баласы итеп тоюы иң элек аның иҗатында – халык җырларында, әкиятләрдә, төрле уеннарда чагылыш тапкан дип нәтиҗә ясала.

Укытучы укучыларга: «Без бүген эндәшләр турында сөйләшербез, ә аның нәрсә икәнен белү өчен, безнең дусларыбызны тыңлап карыйк», – дип, китапка мөрәҗәгать итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектәге Алмаз, Нур, Дәреслек, Гөлназ репликалары белән эшләнелә. Алмаз, Нур, Гөлназ әңгәмәсе дәресне иркле сөйләшү рәвешендә алып барырга мөмкинлек бирә. Балаларның табигатьтә ял иткән көннәрен искә төшерү, әйтик, «Кояшны чакырасыгыз килгәне булдымы?» – дигән сорауны киңәйтеп, балаларның истәлекләрен яңарту аша дәвам итү укучыларда кызыксыну уята. Укытучы: «Табигатьтә рәхәтләнеп ял итәргә җыенганда гына, болытлар кояшны каплый, я су коенып чыккач, кояш болытлар артына кача. Шулвакыт күңелегездә «их, кояш тизрәк чыкса ярар иде» дигән теләк туа. Ләкин сез кояшка эндәшмисез. Ни өчен? Сез чакыруга кояш чыгачагына ышанасызмы?» – дип сорый ала. Балаларның күбесе ышанмавын әйтә. Укытучы: «Ә безнең бабаларыбыз ышанган. Алар табигатьне кеше кебек үк җанлы итеп күз алдына китергән. Әле сөйләшә белмәгән нәни балага кошлар кайтканда тел алып кайта, тәпи дә йөри башламаган сабыйга көзен торналар тәпи калдырып китә дип уйлаганнар. Олылар да, балалар да табигать белән сөйләшкән, ярдәм сорап та, уен формасында да мөрәҗәгать иткәннәр. Һәркем аңа үзенчә яра-

тып, ялварып эндәшкән. Бу эндәшләр, телдән-телгә күчеп, халык арасында таралган. Балалар төрле бөҗәкләргә үз итеп, аларны ишетә һәм аңлый дип эндәшкәннәр. Өлкәннәр тормышында да, балалар уенында да табигатькә эндәшүләр (эндәшләр) барлыкка килгән», – дип аңлата ала. Әлеге фикерне дәлилләп, Гөлназның камкага эндәшен укып, сөйләшү үткәрелә. Салманың нинди ризык булуы белән дә танышалар. Алга таба яңгырга эндәш укыла. Яңгыр боткасы пешерү турында да әйтеп узарга һәм яңгырның ни өчен муллык, туклык белән янәшә килүен аңлатып китәргә мөмкин. Корылык кешеләр өчен ачлык буларак күзалланганлыгын искәртәбез.

Материалны биргәндә, видеодәрестән тә файдаланырга мөмкин.

Алга таба Фоат Садриевның «Яңгыр, яу, яу, яу!» хикәясе укыла.

Хикәя белән төрлечә танышырга: укытучы укырга, укучыларның үзләреннән дә укытырга була. Укучылар, хикәя белән танышкач, үзләре аңламаган сүзләрен билгелиләр. Укытучы ярдәме һәм сүзлек белән аларның мәгънәләренә төшенәләр. Хикәядәге малайларның исемнәренә дә игътибар иттерәбез. «*Тургай* еш очрый торган исем түгел. Ул нинди мәгънә аңлата дип уйлыйсыз? Ә сез *тургай* исемле кошны күргәнегез бармы?» – дип сорарга мөмкин.

Укытучы шагыйрьләребезнең тургайны табигатьнең йөрәге белән чагыштырганлыгын әйтеп, аңлатып китә ала. Ни өчен автор үзенең героена шундый исем бирде икән? Җавап биргәнче, хикәядән Тургай турында сүз барган урыннарны табып укыта алабыз. Аның җиләкләр белән сөйләшүе, бөҗәкләрдән курыкмый аралашуы, табигатьне ихлас яратуына игътибар иттерәбез. Укучылар алда китерелгән сорауга җавап бирәләр. (Табигатьне яратканга, аның белән сөйләшә, аңлаша торган малай булганга, автор аны Тургай дип атый. Фоат Садриевның «Тургай» исемле китабын күрсәтергә мөмкин.)

Алга таба сорауларга җаваплар алына. Сорауларга җавап бирү ирекле сөйләшү, бер-берсен тулыландыру мөмкинлеге белән барганда, балалар үзләрен иркенрәк тота. 9 нчы сорау беренче сый-

ныфлар өчен авыррак. Сыйныфта төрле милләт балалары булса, бу сорауга җавап җиңел табыла. Әгәр авырлык туса, укытучы ярдәмгә килә. Мәсәлән, төрле халыклар камканы төрлечә атый. Казакъча – хан кызы, башкортча – Алла сыеры, русча – божья коровка һ.б.

*Башкорт халык авыз иҗаты үрнәге булган эндәшләр белән таныштырабыз.*

Яу, яу, яңгырым,
Шаулап ашлыклар уңсын!
Башакларның очлары
Ач булмасын, тук булсын!
Ындырларда игеннәр
Аз булмасын, күп булсын!

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучылар эндәшләр турындагы белемнәрен гомумиләштерә. «Эндәшләрнең авторы бармы? Аларны кем иҗат иткән? Алар хикәягә яки шигырьгә охшашмы? Ни өчен алай уйлыйсыз? Балалар һәм өлкәннәрнең нинди эндәшләре белән таныштык?» дигән сораулар тәкъдим итәбез. Балалар *эндәшләр* төшенчәсенә билгеләмә бирә. (Кешеләрнең кояшка, яңгырга, бөҗәкләргә мөрәҗәгате эндәшләр дип атала. Аның авторы булмый.) Китаптагы төшенчә белән танышалар һәм үзләре дә эндәш иҗат итеп карыйлар. Моның өчен терәк сүзләрне укытучы бирә ала. Әйтик, чишмәгә су сорап, каргага яз алып килүен, урманга җилдән саклавын сорап һ.б. Мәсәлән:

Чишмә, чишмә!
Йөгрек чишмә,
Чылтыр чишмә,
Эчер салкын суыңны,
Яшермә.

Кеше һәм табигать бербөтен: табигать кешене тукландыра, җылыта, киендерә һәм матурлыгы белән сөендерә. Без дә табигатьне сакларга тиеш, дигән нәтиҗәгә киләбез.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Карга әйтә: «кар-карр!»

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – татар халкына хас йола (Карга боткасы) һәм балаларның уеннары белән танышып, халкыбызның рухи мирасына мәхәббәт уяну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иҗади күзаллау, күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу, кызыксынучанлык күрсәтү, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – *тизәйткечләр* һәм *санамышлар* төшенчәләрен аңлау, гамәлдә куллана белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** слайд, проектор.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

Табигать кочагында саф һавада уйнау сәламәтлек өчен файдалы булуы, компьютер артында озак вакытлар утыру, телефоннар белән уйнау, телевизор карау, киресенчә, төрле авыруларның сәбәбе булганлыгы турында сөйләшү дәреснең темасын билгеләргә ярдәм итә. (Сабантуйда уздырыла торган уеннар күмәк уеннарга мисал була ала.)

«Балалар, сез уйнарга яратасызмы? Нинди уеннар уйныйсыз? Табигатьтә күмәк уеннар уйнаганыгыз бармы? Сез аларны үзегез оештырасызмы? Өлкәннәр ярдәмендәме? Уйнаганда, санамышлар кулланасызмы? Тизәйткечләр әйтеп ярыш оештырганыгыз бармы? Ә алар турында беләсегез киләме? Әйдәгез, бүген дәрестә санамышлар һәм тизәйткечләр турында сөйләшик», – дип тәкъдим итeлә.

**III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Әнә безгә Алмаз килеп җитте, саф һавада булганы әллә кайдан күренеп тора. Үзе шат, битләре алсуланган. Әйдәгез, Алмазны тыңлыйк әле», – дип, Алмаз репликасы һәм Карга боткасы турындагы язма белән таныштырырга мөмкин.

*Ялан* сүзенә игътибар итү кирәк, шуның аша дәреслектәге рәсемгә күчеп, анда да ялан сурәтләнүен билгелибез. Бу исә, рәсемгә карап, хикәянең кыскача эчтәлеген сөйләүгә юл ача.

Алга таба Гөлназ, Алмаз репликалары тизәйткечләр һәм санамышлар, аларның үзенчәлеге белән таныштыруга ярдәм итә. Дәрестә тизәйткечләрне һәм санамышларны укып кына түгел, аларның тормышта кулланылышын да аңлату кирәк. Тизәйткечләр авазларны дөрес әйтергә, охшаш гыйбарәләрдә аларны ялгыштырмаска, урыннарын алыштырмый әйтергә өйрәтсә, санамышлар оештыру, уеннарда гадел булуның бер чарасы да. Тизәйткеч һәм санамышларны дәресләрнең төрле этабында (башлам, ял итү, йомгаклау һ.б.) кулланырга мөмкин.

Сорауларга җавап биргәнче, Хөрмәтле дәреслек тәкъдим иткән төшенчәләргә билгеләмә белән танышу кирәк.

Татар мәктәпләрендә Нури Арслановның «Яз» шигыре өйрәнелә.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектәге сорауларга җавап табу белемнәрне ныгытырга ярдәм итә.

Дәрестә алган белемнәрне файдаланып санамыш иҗат итү белемне ныгыта, иҗат эшчәнлегенә этәрә.

**V. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Ямьле җәй житә-ә-ә!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – матурлыкны күрә белү, эстетик зәвыкка ия булу, туган җир табигатенә мәхәббәт туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – башкалар фикерен тыңлау, фикерләүдә һәм күзаллаудагы төрлелекне кабул итә алу; әңгәмәдә катнашу, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үз фикерен әйтә белү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ш. Галиевнең «Тәмле җәй» (татар мәктәпләрендә Ф. Зарифның «Татлы җәй» хикәясе дә) шигыренең эчтәлеген сөйли белү, тел-сурәтләү чараларын таба алу; әсәр геройларының гамәлләренә бәя бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** слайд, проектор, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы, дәреслектәге рәсемгә укучыларның игътибарын юнәлтеп, дәрес темасын әйттерә ала.

**III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Җәй нинди ул?» дигән сорауга дәреслек геройлары ярдәмендә җавап эзләнелә. Һәр укучыга үз фикерен әйтү һәм башкаларны

тыңлау мөмкинлеге тудырыла. Җәй турында әйтелгән фикерләр гомумиләштерелә.

«Шагыйрь Шәүкәт абый Галиев җәй турында менә ничек кыска һәм матур итеп әйтеп бирә алган», – дип, укытучы шигырь белән таныштыра. Шигырьне укыгач, сүзлек белән эш башкарыла. Шигырьнең эчтәлегенә укучылар тулысынча төшенсен өчен: «Ни өчен җәй көне аланда җиләк исе килә? Җәйнең матурлыгын тагын нинди сүзләрдән аңлыйбыз?» – кебек сораулар бирергә мөмкин.

Әлеге биремнәрдән соң китапның 156 нчы битендәге рәсемгә нигезләнеп, җәй турында сөйлиләр (бу рус мәктәбе өчен), ә татар мәктәбендә укучылар Алмаз алып килгән Фирдәвес Зарифның «Татлы җәй» хикәясен укып, сүзлек һәм сораулар белән эшлиләр.

Әлеге теманы яктырткан видеодәрес язмасы да бар.

**IV. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәрес башында куелган «Җәй нинди?» дигән сорауга җавап алына.

«Син җәйне яратасыңмы? Көтеп аласыңмы? Җәй көненә планнарың бармы, вакытыңны ничек үткәрергә уйлыйсың?» һ.б. сораулар ярдәмендә ирекле әңгәмә корырга мөмкин, бу очракта укытучы сорау бирүче түгел, әңгәмәдәш булса яхшы. Ул балалар әңгәмәсенә ихласлык өсти, табигый сөйләшүгә алып чыга.

**V. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Нәрсәләр белдек?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – җаваплылык тою.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – куелган уку максатын аңлау һәм чишү юлларын табу, үз фикереңне җиткерү һәм дәлилләү, гомумиләштереп нәтиҗә ясау, иптәшләреңнең җавапларын бәяләү, үзбәя.

*Предмет нәтиҗәләр* – укуның шәхси үсеш өчен кирәклеген аңлау, әдәби әсәрләрне, әдәби төшенчәләрне белү, куллана алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 1 нче сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/.

**Җиһазлау:** слайд, проектор.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы:

– Күрәсез, балалар, ямьле җәй җитеп килә. Беркадәр вакытка мәктәп, китапларыбыз белән хушлашыр чак җиткән. Бүген без Дәреслек, Алмаз, Гөлназ һәм Нур белән дә саубуллашып торабыз.

Укытучы әлеге рухта башлап, укучылардан «Әдәби уку» дәресенә мөнәсәбәтләрен, кызыксынуларын ачыклый. Кайсы язучы, нинди әсәрләр хәтерләрендә калганлыгын, үзләре өчен нинди яңалык белүләрен, нәрсә бик тә ошавын, нәрсәнең авыр булуын сорашып, әңгәмә үткәрәбез. Китап буенча йөгерек кенә карап узарга да була. Укучылардан Алмаз, Гөлназ, Нур турында фикерләрен әйттерергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Хөрмәтле Дәреслек репликасы аша уку мәсьәләсе куела. Үткәннәрне искә төшереп, белемнәребезне тикшерәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укытучы белемнәрне тикшерүнең төрле алымнарын куллана ала. Мәсәлән, сорауларга җавапларны табуны жирәбә уены белән алып барырга була. Сыйныфтагы укучылар санынча (күбрәк тә

мөмкин) жирәбә эшләнә. Анда дәреслектәге кабатлау өчен тәкъдим ителгән сорауларны һәм укытучы үзе теләгәннәрне дә файдалана ала. Һәр укучы бер сорау алып, аңа мөстәкыйль җавап бирергә мөмкин. Әгәр сыйныфта авыррак үзләштерүчеләр күбрәк булса, партага бер жирәбә (бер сорау) алып, җавапларны парларда әзерли алалар. Бу өлешкә йомгак ясагач, укучыларны мактап, икенче өлеш уенга күчәбез. Уенны да төрле алымнар белән үткәрергә мөмкин.

Гөлназ репликасы дәресне тәмамларга ярдәм итә. Аның китапханәсе белән танышу аша укучыларга җәйге биремнәрне аңлатып үтәргә була.

**V. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар дәрескә нәтиҗә ясыйлар.

Дәреслек, Гөлназ, Алмаз, Нурга үзләренең теләкләрен җиткерәләр. Ахырдан геройларның репликасы укыла. Укытучы җәйге биремнәрен җиткерә. Аларны матур открытка формасындагы кәгазьдә эшләргә мөмкин. Аны укучының исемен язып, ахырга Дәреслек, Гөлназ, Алмаз, Нурдан дип күрсәтергә дә була.

Учебное издание

**Абдуллина** Дилария Маратовна
**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна

**ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ**

**1 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования, работающих
с учащимися, изучающими татарский язык как родной

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Абдуллина** Диләрия Маратовна
**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфатовна

**ӘДӘБИ УКУ**

**1 нче сыйныф**

Методик әсбап
Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *Л.Г. Шәрифуллина*
Рәссамы *Д.Л. Нәүрузова*
Компьютерда биткә салучысы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*

Подписано в печать с оригинал-макета 10.04.2023
Формат 60x84 1/16. Бумага офсетная.